Мөнәвир ФАЗЛЫЕВ



# АГЫМ СУЛАР

УДК 802/809.30
ББК 81.2я2
Ф 24

**Мөнәвир ФАЗЛЫЕВ**

**АГЫМ СУЛАР**
Шигырьләр, җырлар, фельетоннар

**Мунавир ФАЗЛЫЕВ**

**ТЕКУЩИЕ ВОДЫ**
(Стихи, песни, фельетоны)

**«Хәтер» нәшрияты**
Нәшерлек эшчәнлегенә 184 нче таныклык 16.04.97 дә
ТР Матбугат һәм информация министрлыгы
тарафыннан бирелде.

420014, Казан, Кремль, Казан Кремле музей-тыюлык
дирекциясе бинасы, 5 нче бүлмә, тел. 92-56-01.

Форматы 84×108 $^1/_{32}$. Шартлы басма табак 3.
Офсет ысулы белән басылды. Офсет кәгазе № 1.
Заказ 396. Тираж 1000

ISBN 5-900004-35-X

© «Хәтер» нәшрияты, 2000
© М. Фазлыев, текст, 2000

Отпечатано с готовых диапозитивов
в Марийском полиграфическо-издательском комбинате
424000, г. Йошкар-Ола, ул. Комсомольская, 112

# ШИГЫРЬГӘ МӨКИББӘН КҮҢЕЛ

Моңарчы билгесез шагыйрь Мөнәвир Фазлыевның шигырьләрен миңа «Казан утлары» журналы мөхәррире (хәзер — Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары), шагыйрь Шаһинур Мостафин танышып чыгу өчен биргән иде. Мөнәвир белән алар 1998 елның мартында тугандаш Башкортостанның Яңавыл районында, Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев һәм танылган җырчы-тальянчы, Башкортостанның һәм Татарстанның атказанган артисты Фән Вәлиәхмәтов белән бергә, әдәби-музыкаль очрашулар үткәреп йөргәндә танышканнар. Яңавыл районының Истәк авылында туган Мөнәвир хәзер дә шунда яши һәм балалар укыта икән.

Мөнәвир Фазлыевның шигырьләр җыелмасын кулыма алганда, әйткәнемчә, мин аның иҗатын бөтенләй диярлек белми идем. Билгесез авторларның беренче кулъязмасы белән байтак танышырга һәм бик йомшак әсәрләр белән очрашырга туры килгәнгә, турысын әйтим, Мөнәвирнең дә кулъязмасын шикләнебрәк алдым. Дөрес, аны университетның мин эшләгән татар бүлегендә укыган студенты буларак күптән белә идем. Шәехзадә Бабич турында диплом яклавы һәм Бабич әсәрләренең шактый тулы җыентыгын әзерләп бастыруы да миңа мәгълүм иде. Ә менә шагыйрьлеге хакында белми идем. Шундый хәлдә Мөнәвирнең кулъязмасы белән таныша башладым. Җитмәсә, кулъязмадагы беренче шигырьләр бигүк тәэсир дә итмәде. Әмма кулъязманың эченә керә барган саен фикерем дә үзгәрә барды. Шагыйрь икән бит ул Мөнәвир Фазлыев! Гомере буе шигырь язган һәм җитлеккән шагыйрь. Эзләнүчән, укучыга үз әйтер сүзе булган һәм, үзе әйткәнчә, “шигырьне гомерлек юлдашы иткән” шагыйрь икән ул. Әмма Мөнәвир аларны, күрәсең, киң җәмәгатьчелеккә чыгарырга ашыкмаган. Үзенең «Ягез, авыз итик!» дигән шигырендә ул моны:

*Өлгергән күп җимеш арасында*
*Минекеләр яшел төслерәк,* —

дип аңлата. Тыйнак кеше, тыйнак шагыйрь сүзләре бу. Әмма һич тә көчсезлек һәм юашлык түгел. Мөнәвир — үз

чоры белән бергә атлаучы, заман агымының уртасыннан торып көрәшүче лирик.

*Кара болытларны пыр туздырам,*
*Әйләнәм дә җилгә шулчакта.*
*Күктән Җирнең гүзәллеген күзләп*
*Очам вакыт белән бер сафта, –*

дигән сүзләре аның күпчелек әсәрләренең төп аһәңен белдерә. Мөнәвир Фазлыевның шигырьләре җыйнак, төзек һәм музыкаль яңгырашлы, хисләре җылы һәм самими:

*Минем дә, агым сулардай,*
*Хисләрем ташкан чагы.*
*Еракларга китәмен дә*
*Әйләнеп кайтам тагы...*

Әйе, Мөнәвир – үз туган ягының җырчысы. Ул үз авылдашлары, үзе укыткан балалар белән бергә яши, аларның уй-хисләрен матур итеп шигырьгә күчерә.

Мөнәвир – туган җирнең гүзәллекләренә сокланып, аның матурлыгын саклау өчен борчылып яшәүче гамьле шагыйрь. Кешеләрнең бер-берсенә игътибарлы булып, мәхәббәт һәм дуслык хисләрен кадерләп яшәүләрен җаны-тәне белән тели ул. Шуңа күрә күп кенә шигырьләре балалар дөньясына багышланган. Ә инде гомере буе укытучы хезмәтен башкарган кешенең балалар дөньясын алар, психологиясен яхшы белеп язуына шикләнмәскә мөмкин.

Бу җыентыкның өченче бүлеге юмор һәм сатира әсәрләреннән гыйбарәт. Монда да Мөнәвирнең теше үткен, көлүе шактый ук көчле. Кыскасы, Мөнәвир Фазлыевның бу җыентыгы шигъриятебезгә әйбәт шагыйрь килүен күрсәтә дип, һич шикләнмичә, әйтә алам. Ягез, авыз итик аның шигъри җимешләрен! Озын киләчәк һәм яңа иҗат үрләрен яуларга язсын Мөнәвиргә.

Мөхәррир Зәет МӘҖИТОВ.
30 сентябрь, 1999 ел.
КАЗАН каласы.

## ЯГЕЗ, АВЫЗ ИТИК!..

Кулларыма көн дә каләм алам,
Үзем язам, үзем тартынам;
Дуслар әйтеп бетермәгән хисләр,
Ашкынулар миндә барсыман.

Акыл көче хисләр ташкыныннан
Булгангамы әллә көчлерәк,
Өлгергән күп җимеш арасында
Минекеләр яшел төслерәк.

Өлгерсен, дип, кәгазьләргә төреп,
Шүрлекләргә куйдым тутырып.
Файдасы шул булды: шүрлек сынды,
Күбесе бетте изелеп, сытылып.

Пешкәннәрен, исән калганнарын
Сайлый-сайлый гомер кичердем.
Җимешләрдән, ягез, авыз итик,
Хөкемегезгә сезнең китердем...

# ВАКЫТ ТИЗЛЕГЕННӘН УЗ, КҮҢЕЛЕМ!..

## *Лирик шигырьләр*

Гөлбадранкай үсә юл читендә,
Сары калфагына сокланам.
Нинди матур аның шул халәте –
Үтеп китә алмый тукталам...

### ВАКЫТ ТИЗЛЕГЕННӘН УЗ, КҮҢЕЛЕМ!..

Ия булып бөркет канатына
Күтәреләм зәңгәр һавага.
Нинди хикмәт: менеп җиттем дигәч,
Баш өстемдә болыт кабара.

Кара болытларны пыр туздырам,
Әйләнәм дә җилгә шулчакта.
Күктән Җирнең гүзәллеген күзләп,
Очам вакыт белән бер сафта.

Бизгәк тоткан кебек Җир тетрәнә
Яңа ракеталар шартласа,
Нәрсә булыр, түземлеген җуеп,
Орбитадан читкә атласа?..

Вакыт тизлегеннән уз, күңелем,
Әйләнеп кайт барган җиреңнән.
Өзелмәсен Туган җир гомере
Кешеләрнең вәхшилегеннән!

## АГЫМ СУЛАР

Яр читендә басып торам
Су ташыган чакларда.
Гөрләвекләр агып төшә
Ничәмә юл-чатлардан.
— Әйтегезче, агым сулар,
Барасыз кай якларга?
— Безне көтә зур елгалар
Еракта, еракларда.

— Озаккамы китәсез? – дип,
Сорадым юксынганнан
Ярларга килеп бәрелгән
Тынгысыз дулкыннардан.

Минем дә, агым сулардай,
Хисләрем ташкан чагы.
Еракларга китәмен дә
Әйләнеп кайтам тагы...

## ГӨЛБАДРАНКАЙ

Гөлбадранкай үсә юл читендә,
Сары калфагына сокланам.
Нинди матур аның шул халәте –
Үтеп китә алмый тукталам.

Тукталам да таҗларыннан сыйпыйм,
Ә ул назланырга ярата.
Көязләнеп башын аска ия,
Хуш исләрен җилгә тарата.

Күкрәгенә орынып исә җилләр,
Тибрәндереп зифа буйларын.
Өзеп алырга дип үреләм дә
Кире тартып алам кулларым.

Гөлләр диңгезенә керсәм генә
Күңелкәем илһам, дәрт алыр.
Һәркем өзсә иркә чәчәкләрне,
Табигатьтә нинди ямь калыр?

## БӘЛКИ, ГАФУ ИТӘРСЕҢ...

Аерылыпкиткәч тә, арттан
Килерсең, дип уйладым.
Ялынырыңа ышандым,
Тик беркатлы булганмын.

Икебез ике утрауда,
Арабызда дулкыннар.
Йөгереп кире кайтыр идем,
Юлларымда упкын бар.

Үземне әллә кем күреп,
Хаталанганмын икән.
Әче телләнеп сине гел
Җәфалаганмын икән.

Миннән башка кыен булыр,
Ничек дөнья көтәрсең?
Йөрәгең таш түгелдер бит,
Бәлки, гафу итәрсең?!

## ЧИШМӘКӘЙ

Чишмәкәй, мин мәңге гашыйк сиңа,
Җырларыңа, салкын суыңа.
Борма-борма көмеш юлларыңда
Уйнаклаган кояш нурына.

Юмартсың син – Туган җирем кебек,
Моңлысың син – сайрар кош сыман.
Дәртлесең дә үзең, татлысың да –
Буйга җиткән сылу кыз сыман.

Җырлый-җырлый ага тонык сулар,
Алы да юк аның, ялы да...
Чишмә сукайлары ширбәтләнә
Сөйгән ярым булса янымда!..

## КИТМӘС ИНДЕ

Китми яннан... "Кит инде, кит!" –
Дип кусам да,
Бакчалардан өйгә кереп
Утырсам да,

Гөрләп аккан чишмә җырын
Тыңласам да,
Җилгә каршы йөзем куеп
Тын калсам да.

Китми яннан – ялынсам да,
Ялварсам да,
"Онытыйм!", – дип, өзгәләнеп
Гел янсам да.

Китмәс инде – Мәхәббәтнең
Чыны шулдыр...
...Каләм җаным, сиңа ирек,
Җырлар тудыр!..

## ӨЗМӘ ЧӘЧӘКЛӘРНЕ

Өзмә, өзмә чәчәкләрне,
Чәчәкләр җимешләнсен.
Орлыклары өлгергәнче
Нурланып көмешләнсен.

Өзмә, өзмә чәчәкләрне,
Тилмереп шиңмәсеннәр.
Чәчәкләр рәнҗешен алма,
"Бу – явыз!", – димәсеннәр.

Өзмә, өзмә чәчәкләрне,
Үссеннәр имин генә.
Өзсәң өз тик берне генә,
Үзеңә тиңен генә!..

## КӨЗГЕ ГӨЛЛӘР

Сары яфракларны җил туздыра,
Кара көзләр җәйгән канатын.
Ә мин кырда җыям чәчәкләрне –
Кар астында туңып калмасын!

Куырылып салкын кырауларда
Күшеккәннәр көзге яңгырда.
Хәлсезләнеп бөгелеп төшсәләр дә
Тырышалар исән калырга.

Утырттым мин сулы савытларга
Алып кайтып җылы өемә.
Терелгәнгә гөлкәй-сылукайлар,
Торып-торып, күңелем сөенә.
Ятимнәр дә көзге гөлләр төсле,
Сагышланган яшьле күзләре...
...Балаларын ташлаган аналар
Хәтерләтә ямьсез көзләрне.

## ТЫНЛАРМЫН

— Җыелышка бар, – диделәр,
Бардым инде, тыңладым.
Халыклар таралган иде,
Соңладым шул, соңладым.

Мәҗлескә мине дәштеләр,
Бардым инде, тыңладым.
Кунаклардан җилләр искән,
Соңладым шул, соңладым.

Кызлар уенга чакырды,
Бардым инде, тыңладым.
Кияүгә китеп беткәннәр,
Соңладым шул, соңладым.

Соңгы юлга дәшсәләр дә
Бармый калмам, тыңлармын.
Гадәтем сеңгән каныма,
Соңлармын шул, соңлармын.

## ӨЙ ТОРА КӨЛЕП КЕНӘ

Сөбханалла, мәчет кебек
Яңа өй җиткергәнсез.
Бу кадәр агач-ташларны
Ничекләр китергәнсез!

Кем соң сезнең "башковитый",
Әнфисәме, Фәнитме?
Әллә туганнар җыелып,
Бу зур эшне хәл итте?

Анык кына әйтә алмыйм,
Ничек булса да булган.
Энекәшләр нәкъ Казанда
Күркәм өй коеп куйган.

Үзенә өй салучылар
Шәһәрдә сирәк була.
Тернәкле, оста егетләр
Авылда ешрак туа.

Бу өлкәдә мин үземне
Мактый алмыйм, кәнишне:
Мастерок тотсам – "келт" сына,
Балтага кул ябышмый.

Тотындыммы берэр эшкә,
Үз башым белән уйлап,
Һич очына чыга алмый
Йөрим җанымны кыйнап.

Энекәшләр алай түгел,
Энекәшләр булдыра.
Шуңа күрә, мин, масаеп
Өй туенда утырам.

Хуҗалар мөлаем булгач,
Тора өй көлеп кенә.
...Яшәгез бер-берегезне
Кадерләп, сөеп кенә!

## ДӨНЬЯ МАТУР

Дөнья иркен хөр күңелле кешеләргә,
Берсен-берсе хөрмәт иткән күршеләргә.
Кулларында кош уйнаткан ир-атларга,
Иман нурын өстәп торучы затларга.

Дөнья якты берсен-берсе аңлаганга,
Кояш күрсә генә алма алмалана.
Кара болыт кабарыр дип ышанмасаң,
Нәфесеңне тыя белсәң, тышауласаң.

Дөнья матур сөенгәнгә, сөелгәнгә,
Күкрәгеннән гыйшык уты түгелгәнгә,
Саф йөрәген бүлгәләми яшьнәгәнгә,
Тиң мәхәббәт бакчасында яшәгәнгә!..

## ЯҢАВЫЛ ПЛЮС КАЗАН

Яңавыл – Казан арасын
Җырлап кына барасы.
Сөйгән ярым Казан кызы,
Мин – Яңавыл баласы.

Кушымта:
Машина тәгәрмәчләре
Тик бер җыр җырлый һаман:
"Яңавыл плюс Казан да,
Яңавыл плюс Казан!"

Яңавыл – Казан арасын
Поездлар шаулап үтә.
Һәркөн ут йотып сөйгәнем
Мине сагынып көтә.

Кушымта.

Машина тәгәрмәчләре
Майламасаң әйләнми.
Сагынганда, саргайганда
Бер күрүе әллә ни!

Кушымта.

## КИТМӘГЕЗ, КЫЗЛАР...

Китмәгез, кызлар, китмәгез,
Чит җирләрдә авыр бит.
Сезнең туган мәркәзегез
Шәһәр түгел, авыл бит!

Авыл ямен, суы тәмен
Алып китәсез инде.
Сөлек кебек егетләрне
Ялгыз итәсез инде.

Туган җирен, сөйгән авылын
Ярата кайсыбыз да...
Гомергә торып калыгыз,
Кунакка кайтыгыз да!..

## ЯРАТАМ МИН ТУГАН АВЫЛЫМНЫ

Яратам мин туган авылымны
Шунда туып, шунда үскәнгә.
Сусаганда салкын чишмәләрнең
Учлап-учлап суын эчкәнгә.

Яратам мин сабан туйларында
Гармуннарга кушылып җырларга.
Сөйгән ярым белән таңга кадәр
Сандугачның моңын тыңларга.

Яратам мин туган авылымны –
Әнкәм кебек бердәнберемне.
Мин бәхетле булыр идеммени
Алыштырсам газиз җиремне?!

## ШАЯРТУ

Алъяпкычың бәйләп алдың да син,
Җиңнәреңне куйдың сызганып,
Табаларга вак-вак коймак тездең
Таң нурлары кебек кызарып.

Әллә оялыпмы, әллә юри
Күзләреңне миннән яшердең.
— Уңайсыз ла син каршымда торгач,
Уф, йөрәгем, бетте, пешермим!..

Мин сокланам: “Иркәм, бит очыңа
Он буялган, нинди матур!“ – дип.
Күзләремне ала алмыйм синнән,
Каян килде шундый батырлык!

## ТЕЛЕВИЗОР

(Җыр)

Телевизор карап кына
Күзләрем талмас әле.
Бер дикторга гашыйк булдым,
Гаепкә алмас әле.

Кушымта:
Телевизор, телевизор,
Замана могҗизасы.
Бөтен дөнья уч төбемдә,
Илләрне юк гизәсе.

— Хәерле иртә! – дип дәшә
Каршыма килеп кенә.
Нур өстенә нур өстәлә
Сөйләгәч көлеп кенә.

Кушымта.

Күзләре кара бөрлегән,
Кыйгач кара кашлары.
Әллә кайчан күргән булсам,
Сөймәс идем башканы.

Кушымта.

Уфа дикторлары кебек
Матур кызлар бар микән?
Белсәң иде, телләрендә
Шикәр микән, бал микән?

Кушымта.

## ИЗГЕ ЖАНЛЫ ӘЛФИЯ

Аккошка охшатам сине
Ак халатыңны кисәң.
Сүнгән өметләр терелә
Палатама син керсәң.

Ягымлы йөзең елмая,
Кояшны көнләштереп.
Күңелемне күтәрәсең
Акыллы киңәш биреп.

Табибларның ихласлыгын
Аңлый тик авыру гына.
Йөрәк җылысын кушмасаң,
Терелтми дару гына.

Фәрештәдәй изге җан ул
Ак халатлы Әлфия.
Авырулар сихәт алып,
Бәхет теләп баш ия.

## ЧӘЧӘКЛӘР

Әйтегез, чәчәкләр,
Кем сезне үстерде?
Күңелне яуларлык
Илаһи көч бирде?

Күр, нинди чәчәкләр
Тирбәлә җилләрдә.
Мин телим иркәмне
Чәчәккә тиңләргә.

И гүзәл, яшь парлар,
Аерылып китмәгез.
Өзелгән гөлләрдәй
Саргаеп кипмәгез!..

## ТАМЧЫЛАР

Тамчылар, тыпылдап,
Тау-ташны тишәләр,
Күңелләр төенен
Бергәләп чишәләр.

Тамчылар бәгыремнең
Кылларын чиртәләр...
Ашыкма, килер көн,
Сөйгәнең иркәләр!..

Тамчылар, нур чәчеп,
Җемелди үләндә.
Өзелмә тамчыдай
Бер сөям дигәнгә!..

## ЙОЛДЫЗЛАР - КҮРӘЗӘЧЕ

Нинди язмыш көтә икән
Буйга җиткән кызларны?
Җиткән кызлар сердәш итә
Җидегән йолдызларны.

Җиде төн урталарында
Йолдызлар яна күктә.
Җидегән йолдызны күрсәң,
Теләк теләми үтмә.

Җидегән йолдызны сана
Бер түгел, җиде кабат.
Сөйгәнең калмасын ятка,
Карат үзеңә, карат.

Җидегән йолдызны санап,
Мендәргә сал башыңны.
Төшләреңдә син күрерсең
Киләчәк язмышыңны.



[illegible library stamp]

Гомерлек ярың булырмын
Керсәм татлы төшеңә.
...Йолдызлар – күрәзәче ул
Гашыйк булган кешегә!

## КАЙДА СОН СЕЗ?

Кайда соң сез, кайда, минем улларым,
Җылый-җылый сүрелде күз нурларым.
Ишеттерергә телим хәбәремне,
Беләсегез киләдер хәлләремне.

Әтиегезне салдым җир куенына,
Быел ун ел тула соңгы туена.
Булгансыздыр башлы-күзле, ир-ата,
Кулларыгыз нинди эшләр кыйрата?

Балаларыгыз берәүме, икәүме?
Алар да үзегез кебек иркәме?
Исемнәре кем: Степан, Иванмы?
Черетүегезме милләт, иманны?

Әллә сату итәсезме базарда?
Кәгазь тапмыйсыздыр бер хат язарга.
Адресым шул, исемем генә яңа:
Балалыдан баласыз калган ана!

## ЭЗЛИМ

Тукайны эзләп таптым мин
Укып Бабич китабын.
Бабич канатын ныгыткан
Бакчасында Тукайның.

Олы шәхесләрне таптым,
Эзлим хәзер үземне.
Халкым нәрсә дияр икән
Әйтсәм йөрәк сүземне?

Ничә еллар шул сорауга
Җавап эзләп баш ватам.
Тауга карасам – тау биек,
Тауга шүрләп күз атам.

Әйтә йөрәк: “Икеләнмә,
Башла Бисмилла әйтеп.
Тырыш ташка кадак кага,
Чыга чүлләрне үтеп.

Кайнар йөрәгең типкәнгә
Бары тик куан гына,
Гигантлар арасында син
Булсаң да гном гына“.

## НИГӘ, ӘТКӘЙ, МОҢЛАНДЫҢ?..

Иртәнге талгын, саф һава,
Ат лырт-лырт юртып бара.
Якынлашып килә урман,
Үткәнбез шактый ара.

Әтием тик болай гына:
— Әйдә, малкай! – дип куя.
Каккалый ак дилбегәсен,
Янәсе, атны куа.

— Өшемәдеңме, улым? – дип
Сораштырып алгалый.
— Тирә-ягыңны карап бар,
Күзең йомып калма , – ди.

Җылыта каплап битемне
Җылы куллары белән.
Туңсам әгәр, күлмәген дә
Салып бирәсен беләм.

Чана астыннан сузылып
Ялтырый ике тасма.
Авылым күздән югалды,
Төшәбез үрдән аска.

— На, малкай! – дип кабатлады,
Тарткалап дилбегәсен...
Күңеле ник нечкәргәнен
Килә минем беләсем.

Җырлап җибәрде әтием –
Юлда күңел үсәдер:
— Һаваларда йолдыз, ай, ничәдер,
Ничә санасаң да күчәдер...

Нигә, әткәй, карлы юлда
Таң атканда җырладың?
Җырыңның соңгы сүзләрен
Ишеттерми тын калдың?

...Таңнарда йөрим урманда,
Ишетеп тавышыңны.
Әллә шуңа бәйләдемме
Моңга үз язмышымны?

## ӘНКӘЙ ПЕШЕРГӘН ИКМӘК

Атлан май якты әнием
Кара икмәк телеменә.
Бал да яккач, икмәк белән
Йота яздым телемне дә.

Еллар үтте. Өстәлемдә
Май бар, икмәк телеме дә.
Әнкәй пешергән икмәкнең
Тәмен эзли телем генә.

## МӘХӘББӘТЕҢ БУЛСА

Мәхәббәтең булса, шундый булсын:
Бер-береңнең кадерен белерлек,
Күкрәгеңдә дәртең ялкынлансын,
Алтын туеңда да биерлек.

Мәхәббәтең булса, шундый булсын:
Тормыш матурлыгын күрерлек,
Өй тутырып бала үстерерлек,
Бәхет таҗын бергә үрерлек.

Мәхәббәтең булса, шундый булсын:
Җыерылмасын кара кашларың,
Өмет белән киләчәккә карап
Яңартырсың нигез ташларын.

Мәхәббәтең булса, шундый булсын:
Ил язмышын күтәр җилкәңдә.
Гомер юлларында сынатмассыз
Йөрәкләрне парлап җиккәндә!..

## ТЕПЛОВОЗ

Ашыкма, тепловоз,
Азга, бик азга түз.
Перронда бер яшь кыз
Төшерде миңа күз.

Кушымта:
Тепловоз, тепловоз,
Китмәче, китмәче.
Йөрәгемә ут сипмәче,
Килче, килче яныма, сылу кыз!

Кайчандыр электән
Танышлар идекме,
Әллә соң вагонда
Без бергә килдекме?

Агыйдел суларын
Кичтекме бергәләп,
Чал Урал тавына
Мендекме үрмәләп?

Кушымта.

Ярсыган күңелемне,
Ах, ничек түздерим?
Машинист кычкырта,
Кычкырта өздереп.
Кузгала тепловоз,
Миңа кул сузыла.
Охшаттым Дон кызын
Иделем кызына.

Кушымта.

## СОЛДАТ УЛЫМ - ИЛНУРЫМ

Үтерделәр! Ташлап киттеләр,
Газиз башын таптап үттеләр!
Кан эчендә ята Илнурым,
Төпчек улым минем, күз нурым!..
Нәрсә булды, бәгъром, әйтсәнә,
Уф, егылам, башым әйләнә.
Күз йомыла, йөрәк кысыла,
Үләрмендер мин дә шушында.
Кичә ялга кайткан солдатым,
Ышанычым минем, канатым.
Чү, түз, йөрәк, туктап калма син,
Вакыты ул түгел, аңла син!
Син туктасаң, кем соң үч алыр,
Үтерүчеләр җавапсыз калыр.
Түз, йөрәгем, авыр булса да,
Күзләремә кан-яшь тулса да.
Туктатыгыз! Каны акмасын –
Күтәрегез, җирдә ятмасын!

Салкын тиюе бар улыма,
Кулы, аяклары суына.
Күрсәтегез ашыгыч ярдәмне,
Сез кемнәр соң: бүре, адәмме?
Шаулап ага, әнә, кайнар, кан,
Кемдер, гүя, утта кайнаткан.
Туң җир эри, эри кар, бозлар.
Хәрәкәтсез егет һәм кызлар.
Нишләсен соң, алар ут йоткан,
Әйтерсең лә барсын ток суккан!
Томаланган яшьле күзләре,
Калтырана гәүдә, тезләре –
Күргәне бармыни яшьләрнең
Мондый вәхшәт, мондый мәхшәрне?
Елый үксеп, әрнеп бар халык,
Күкрәгенә ятып, баш салып.
Кара кайгы басты авылны,
Матур иде Илнур, акыллы...

* * *

Күк капусы балкып ачылганда
Ак теләкләр генә теләдем.
Сау-сәламәт, бәхетле бул, дидем,
Гомерең озын булсын, димәдем.
Нигә озын гомер теләмәдем?
Нәрсә бүлде икән уемны?
Шау-гәр килеп сөенеп яшәгәндә
Мин югалттым газиз улымны.
Кошлар кебек очып кайткан идең
Нуры булып бөтен урамның.
Әзмәвердәй егет булгансың бит,
Сиңа карап ничек куандым.
Шомырт кара күзләр, кара кашлар,
Дулкынланып торган чәчләрең
Әсир итте мине. Төшендем мин
Мәгънәсенә шунда яшәүнең.
Улым, бәгъръем, юха телләренә
Ник ышандың явыз дошманның?
Электән үк белә идең дә бит

Гарип икәнлеген ул җанның.
Кайда иде синең ахирәтләр,
Нигә сине ташлап киттеләр?
Чәчәк кебек гомерең өзелгәндә
Ник куркышып артка чиктеләр?
Кайсылары, күрмәмешкә салышып,
Яшеренгән аулак урынга.
Шундый дуслар чын дус буламыни –
Кайгыртмагач дусы турында?!
Кабинада кыйнап, миңгерәүләтеп,
Как урамга ташлап киткәннәр.
Фараларын басып, кабат килеп,
Машинада таптап үткәннәр.
Их, син, дөнья, кайгы сандыгы син,
Ник юл куйдың вәхши үлемгә?
Улым сине матурларга килде,
Матурлый ул җирне бүген дә!
Сәхраларга чыгып эзлим сине,
Тавышыңны кошлар моңыннан.
Күреп, сөйләшеп тә туя алмадык,
Китеп бардың кайткан юлыңнан.
Дошман кулы өзде яшь гомереңне,
Яшьнәп, күкрәп яшәр чагында...
...Сине һәрчак сагынып яшәрбез без –
Рухың тыныч булсын, кайгырма!..

## КУАНАМ МИН...

Язгы җылы җилләр
Назлады күңелне.
Газиз туган җирем
Чәчәккә күмелде.

Канатланды гомер
Кошлар кайткач илгә.
Яшәрде киң кырлар
Тамчы тамгач җиргә.

Куанам мин бөтен
Дөнья белән бергә.
Күк күгәрчен, син дә
Гөрлә әйдә, гөрлә!

## ЯШЕРМӘ КАРАШЫҢНЫ

Яшермә әле карашыңны
Күзләрең йомып кына.
Кояш нурларын яшерә
Караңгы болыт кына.

Очкыны төште бәгыръгә
Керфегең арасыннан.
Кояштан да якты булып
Йөрәгем янасыман.

Дөньяның бар гүзәллеген
Күзләреңә җыйгансың.
Туйганчы бер карыйм әле,
Күңелләрем куансын!

## ИСТӘК - ТУГАН АВЫЛЫМ

Сиреньнәр чәчәк атканда
Яратам хуш исләрен.
Син – минем тере чәчәгем,
Туган авылым – Истәгем!

Кушымта.
Ераклардан балкып тора,
Ни җитә Истәгемә?!
Сөйкемле авылдашларым
Һәрвакыт истә генә.

Сандугачлар белә икән
Кайда оя корырга,
Кайтмаслар иде сагынып
Авылыма – турыга.

Кушымта.

Дәртем таша, көчем арта,
Авылым, синдә җаным.
Синдә минем газиз әнкәм,
Сөеп туймаслык ярым.

Кушымта:
Ераклардан балкып тора,
Ни җитә Истәгемә?!
Сөйкемле авылдашларым
Һәрвакыт истә генә.

## ЧӘЧӘКЛӘР УТЫРА ТЫН ГЫНА

Яфракка кагыла-кагыла
Моңлы җыр агыла-агыла.
Җәйге зур бакчада тик икәү
Сөйләшә җай гына, җай гына.

Түтәлдә чәчәкләр, чәчәкләр,
Үзара сыена-сыена,
Яшь парны таңгача-таңгача
Тыңларга җыена-җыена.

Тулган ай төн буе, төн буе
Ак нурлар сипмәкче, сипмәкче.
Бәхетле яшь парга сандугач
Җыр бүләк итмәкче, итмәкче.

Күкрәкләр күкрәккә кысыла,
Кушыла иренгә иреннәр...
Сандугач, ай йома күзләрен –
Алар бит фатиха бирделәр.

Чәчәкләр утыра тын гына,
Йөрәкләр талпына-талпына...
Шулчакта вәгъдәләр бирелә
Бәхетле киләчәк хакына!

## ЯТСЫНМА

Хисләрем чишмәсе ургыла,
Сыймый ул һич кенә ярларга!
Тиздән Син килерсең — сизәмен! –
Сагынуга – Син дару, Син дәва!

Шундый саф һәм кайнардыр чишмәм –
Көннән-көн агымын арттыра.
Якын дус, тизрәк бул, тизрәк бул,
Шифалы суын эч, ятсынма!

Икебез гел бергә булганда
Әйтерсең үзең дә, ышанам:
— Хисләрең кайнар да, ярсу да,
Нәкъ менә гейзерга охшаган!

## АВЫЛ

Авыл яши арып-талып,
Очын-очка ялгый-ялгый.
Менә-менә яңарам, дип
Үзен-үзе алдый-алдый.

Авылны җыерчык баскан,
Өйләр чүгеп, авызын ачкан.
Теше төшеп, протез капкан,
Колак аппараты аскан.

Авыл бөрешкән суыктан,
Җил ак кардан кибән койган.
Тәрәзәләргә боз каткан,
Котып салкынлыгын җыйган.

Язларын сайрый сандугач,
Сагышларга чут-чама юк.
Кайтмыйлар бит балалары,
Йөрәкләрдә ут яна, ут!

Авыл сагына үткәнен,
Гөрләтеп дөнья көткәнен.
Кыңгыраулы атлар җигеп
Кунак, туйларга киткәнен.

Зур авылдан ун өй калган,
Шул ун өйдә унбер әби.
Ирләрдән гомер итә тик
Җитмеш яшьлек яугир Нәби.

Авыл авыру, хәлсезләнгән,
Диагнозы: картлык чире.
Кем кулына тапшырыр ул
Мирас итеп изге җирне?

## ВӘНЗИР ГАЛИНГА

Вәнзир дус чыгып бастымы,
Нурлар балкый сәхнәдә.
Үземне хис итәм шунда
Тургайлы киң сәхрәдә.

Эчендә әллә кош бармы,
Гармуны сайрап тора.
Беләм, йөрәк түрләрендә
Дәрт ташып, кайнап тора.

Тормышта ямь буламыни —
Гармуннар уйнамаса?!
Күңелеңне тетрәндереп,
Сагыш-моң уянмаса!

## ЮЛДА

Вагон тәрәзәләреннән
Кояш карый үрелеп.
Авыллар килә каршыма
Яшеллеккә төренеп.

Поездны узып йөгерә
Тынгысыз хыялларым.
Күзәтеп киләм Иделнең
Ярларын, кыяларын.

Җәелеп яткан басуларда
Арышлар серкәләнә.
Кая барма, җанга рәхәт,
Күңелләр иркәләнә...

Тәгәрмәчләр җырын тыңлый
Чәчәкләр юл читендә.
Вагон тәрәзәсен ачам,
Җилләр өрсен битемә.

Туган илем – йөрәк түрем,
Чәчкәләргә тиң җирем.
Юлларым калмас өзелеп,
Дөньялар булсын имин!..

## ТАҢНАРДА ТОРЫП

*...багышлыйм*

Таңнарда торып, Кояшкай
Нурларын сипте сиңа.
Шатланып, балкып киләсең
Җимешле җитмешеңә.

Сокланмаска мөмкин түгел
Эшләгән эшләреңә.
Куанып, сөенеп яшә
Үзеңнең көчләреңә.

Агачыннан ерак төшми
Алмагачның алмасы.
Син – мәгърифәткә юл ачкан
Дүрт мөгаллим анасы!..

## КАЙДА, КАЙДА МИНЕМ МӘХӘББӘТЕМ?

Кайда, кайда минем мәхәббәтем,
Тургай булып күктә сайрыймы?
Бал кортлары сыман, юллар үтеп,
Кунар өчен чәчәк сайлыймы?

Кайда, кайда минем мәхәббәтем,
Алып барыр нинди юл гына?
Тирбәләме әллә күл өстендә
Ялгыз аккош сыман тын гына?

## КӨТМӘГӘНДӘ ТАШЛАП НИК КИТТЕҢ?

Йөзең якты, күзең нурлы иде,
Йөгереп чыга идең каршыга.
Килгән саен табын әзерләдең,
Уңган идең эшкә, аш-суга.

Сөйләшеп тә сүзләр бетмәс иде,
Сизми идек вакыт үткәнен.
Без яратып сезгә килә идек,
Була идек синең көткәнең.

Шау-гөр килеп матур яшәгәндә
Кара кайгыларга уралдык.
Һушларыбыз китеп бу хәсрәттән
Чак аякта басып торалдык.

Гомерең аръягына китеп бардың,
Авыру да түгел идең бит.
Яшәргә дә яшәргә иде дә,
Көтмәгәндә ташлап киттең ник?

Ишекләрен оҗмах киң ачсын, дип
Кырыгыңа килдек җыелып...
Изге җанлы гүзәл Әнкәбезнең
Кабере торсын нурда коенып...

## ТЕЛӘК

Һәр мөселманга кадерле
Изге рамазан ае.
Көне-төне теләк теләп,
Сызыла йөрәк маем.
Иманга килсен тугәләр,
Акыл һәм сабырлык бир.
Иминлек килсен дөньяга,
Көлгә әйләнмәсен җир.
Тукталсын сугыш Чечняда,
Телим Ходайдан сорап.
Үтермәгез бәндәләрне
Ит турагычта турап.
Кайда соң кешелеклелек,
Гаделлек, намус, вөждан?
Үтерүчеләр, караклар
Коры чыгалар судан.
Сүнә якты өметләре
Пәһлевандай ирләрнең.
Тир түгеп тапкан акчалар
Кесәсендә кемнәрнең?
Талаш, ызгышудан башка
Эшегез юкмы әллә?
Ничек ил ныгысын инде
Шушы болганчык мәлдә?

И Ходаем, изге ай бит
Якты рамазан ае!..
...Түгелмәсен канлы яшьләр,
Сызмасын йөрәк маем...

## ЮЛГА ЧЫКСАМ

Юлга чыксам, сагышланып,
Моңаеп каласыңдыр,
Уйларың белән артымнан
Ияреп барасыңдыр.

Кулларыңны болгый-болгый
Калма син, Әнкәй, елап.
Әйләнеп кайтырмын сиңа,
Булса да юлым ерак.

Киткәндә озата чыксаң,
Җиңел була юлларым.
Яктырта барыр юлымны
Күңелеңнең нурлары!..

## САГЫНАМ СИНЕ, ӘНКӘЙ!..

Рәсемеңә озак карап торам,
Актарганда альбом битләрен.
Ишетәсеңме, Әнкәй, сызлап-сагынып,
Йөрәгемнең ярсып типкәнен.

Белмим, нигә озын керфекләрем
Кайнар яшьләремә манчыла?
Альбом битләренә тып-тып тама
Күзләремнән аккан тамчылар.

Күкрәгемә сыймый, сагышланып,
Дулкыннардай дулый хисләрем.
Нигә безне кинәт ятим иттең,
Нишләдең син, Әнкәй, нишләдең?

Яшәдең син тормыш кадерен белеп,
Яңа көн туганга куанып.
Сары сагышларны басар өчен
Рәсемең дә ярап куя бит.

Язлар саен шаулап чәчәк ата
Син үстергән иркә гөлләрең.
Татлы төшләр генә булган икән
Бергә дөнья көткән көннәрем!..

## ТУКТАП ТОРЫЙК, ТЫНЛАП ТОРЫЙК...

Әйдә әле урап кайтыйк
Кырларны, тугайларны.
Туктап торыйк, тыңлап торыйк
Сайравын тургайларның.

Кушымта:
Эштән бүтәнне белмисең,
Сөйләшмисең, көлмисең.
Башкалардан кай җирем ким,
Син үзеңне кем дисең?

Бү ярларына басып,
Карыйк су агышларын.
Туктап торыйк, тыңлап торыйк
Шаулавын камышларның.

Кушымта.

Йөрик әле урамнарда,
Мине ялгыз итмәле.
Туктап торыйк, тыңлап торыйк
Йөрәкләрнең типкәнен.

Кушымта:
Эштән бүтәнне белмисең,
Сөйләшмисең, көлмисең.
Башкалардан кай җирем ким,
Син үзеңне кем дисең?

## ҖЫРЛАР ОЧЫРАМ ӘЛЕ

Җил канатына утыртып,
Җырлар очырам әле.
Кайчан да бер юлларыңда
Сиңа очырар әле.

Җил тынып торган арада
Алалсаң иде тотып,
Күңелләреңә хуш килеп,
Калалсаң иде отып.

Ефәктәй сарылса иде
Тынгысыз йөрәгеңә,
Былбылдай сайраса иде
Күңелең тирәгендә!..

## «ӨМЕТ»КӘ

Кар кебек кәгазь өстендә
Өметле эзләр ята,
Шул эзләрдән атлап барсам,
Яшьлегем кире кайта.

Һәр эздә тормыш аһәңе,
Кайнарлыгы хисләрнең.
Сизәм, күңелне яшәртеп,
Садә җилләр искәнен.

Ышанам: шул кайнар эзләр
Чыгарыр олы юлга.
Батырмас саз-сазламыкка,
Җибәрмәс уңга-сулга.

Яңалыкка, изгелеккә
Шул юллар ирештерер.
Күңел күзләрен ачар да,
Дус белән күрештерер.

Яшьлектә кемгә дә авыр
Үз юлларын табуы.
Каләмнәрнең үткенлеге
Яман шешкә дару ул.

Рәхмәт изге эш башлаган
Игелекле яшьләргә...
«Өмет» безгә куәт бирсен,
Илһам бирсен яшәргә!..

## СҮЗЛӘР - ГӘРӘБӘ

Хисләрем – диңгез,
Каләмем – ишкәк.
Корабым – авылым,
Исем – Истәк.

Өметем – татлы,
Теләгем – пакълык,
Йөрим өләшеп
Күңелгә шатлык.

Фикер – алтын җеп,
Сүзләр – гәрәбә.
Тезсәң әгәр дә
Охшар кәрәзгә.

## КУРКАМ...

Авырсам, дусларым
Кайгырыр, дип куркам,
Чөнки бар кешенең
Тормышлары уртак.

Боексам, дусларым
Борчылыр, дип куркам –
Чөнки бар шатлыклар,
Хәсрәтләр дә уртак.

Җырласам, дусларым
Ишетмәс, дип куркам, –
Чөнки бар җырлар да,
Моң-сагыш та уртак.

## БӘБИ ТУЕ

Шатлык артты бала тугач,
Йөзләр балкый – гүя, Кояш!..
Алтыным да, чибәрем, дип,
Сагындырып килгәнем, дип,

Иркәләп үпте әнисе,
Күкләргә чөйде әтисе.
Кунаклар өйгә җыелды,
Ризыктан өстәл сыгылды.

Тәмам кызды мәҗлес халкы
Яшь ананы мактый-мактый,
Җыр тынмады төне буе,
Гөрләп торды бәби туе.

...Шау-шу тынды. Мәҗлес тәмам.
Су сипкәндәй зал буш калган,
Нарасый, алҗып назлаудан,
Нидер эзләде һавадан.

Табалмагач, эче пошып,
Үкседе ул мышык-мышык...
Бишек төбендә дәү әни,
Бәби көйләп: «Әлли-бәү!» – ди.

## ТОРМЫШМЫНИ?

Баш әйләнә, күңел болгана,
Шомлы йөрәк никтер моңлана.
Яшәүләрнең бетте мәгънәсе
Бу буталчык фани дөньяда.

Тормыш тормышмыни – бер хәсрәт,
Күңел гөлем сула әлсерәп,
Аждаһалар котырынган илдә
Шат тормышым кемгә соң кирәк?

Аптырашта калган Газраил,
Тетри дөнья, аза-туза Ил.
Дары төтеннәрен иснәтеп,
Борыныма орынып исә җил.

## КАРА БОЛЫТ

Баш өстемдә кара болыт
Яшергән Кояш нурын.
Кара болыт асларында
Яшәүләре бик кыен.

Шомлы караңгылык баскан
Урам, ишек алларын.
Каршымда бер шәүлә йөри,
Һич тә таный алмадым.

Йөрәгем китте чымырдап,
Җанга тынычлык тапмам:
Әллә үлеләр шәүләсе
Кавказ җиреннән кайткан?

## ЙОМГАК ЯСЫЙМ

Кайчагында үткәннәргә караш ташлыйм,
Гомеремнең агышына йомгак ясыйм.
Әрни күңел, сыкрап-сыкрап тибә йөрәк,
Файда иткән көнем илгә, һай, бик сирәк.

Ничек кенә һәр сәгатем, һәрбер көнем,
Халкым өчен файда итсен икән минем?
Туган җирне мин утырткан гөл бизәсен,
Бар әле, бар ул гөлләргә су сибәсем!

## ХАСТАХАНӘДӘ

Ятам хастаханәдә ах-вах килеп,
Ятам ләкин терелеремне белеп.
Күкрәгем кысыла, һич җитми һава,
Калтырыйм, дер-дер киләм, тәнем яна.

Йөрәгем сызлана әрнеп, башым ут,
Саташтыра, китсәм кайчак басылып.
Тыныч түгел күңелкәем, эзләнә,
Күпне күргән гомерем көйсезләнә.

Русиябез авыру бүген – борчылам,
Халыкларга бирче гакыл, бир чыдам.
Анда комсызлык, фәхишлек, үтереш,
Яши алырбызмы озак шул килеш.

И сихәтлек бүләк иткән табиблар,
Баш ия сезгә авырулар, гарипләр.
Рәхмәт укыйм йолган өчен үлемнән,
Сез – фәрештә, ак халатлы киемнән!

Ярый әле килгәнмен соңламыйча,
Терелттегез, яшимен сызланмыйча.
Мин ышанам: Русия дә савыгыр,
Савыктырыр табиблары табылыр!..

## ТЕАТР

(Уены–чыны бергә)

Түшәктә ятам авырып, газапланам,
Кемдер гүя гәүдәмне кадаклаган.
Саташтыра, шомлы уйлар уйлатып,
Күзләремдә яшен уты уйнатып.

И Ходаем, кызганчы мин бәндәңне,
Чиремне ал, тормышымны ямьләле.
Әллә Тәңрем теләгемне ишеткән,
Хәләлемнең йомшак сүзен ишетәм:

— Соңга калабыз, – ди,– әйдә, тор, юын,
Онытмагансыңдыр ич клуб юлын.
Менә үтүкләнгән күлмәк, галстук –
Ашык, зинһар, башкалардан калышмыйк!

— Ничек барыйм, шыбыр су бөтен тәнем,
Янымда сагалап тора Әҗәлем.
— Терелерсең, ахирәтләрең килгән –
«Яңавыллар театры» диелгән.

— Ничек, ничек? «Яңавыллар» дисеңме?
Бармы Нәфисә һәм Хәбир[1] исеме?
Исемнәрендә биоток бар әллә?
Һушым китте: чирем качты шул мәлдә.

Йөрәгемдә шашкан хисләр ургыла,
Коеныймчы күзләренең нурында.
Һәр чыгышлары сәхнәдә – куаныч,
Пакьландырып, бозыклыкны куа ич.

И сәләтле, илһамлы кардәшләрем,
Хак сүз бит ул: сез – үрнәге яшьләрнең.
Саклаганга киләчәгеn милләтнең,
Халкым зурлый талантлары хезмәтен.

Бик сөендем: биеп һәм җырлап алам,
Театрга шуышып булса да барам.
Театр ул сафландыра күңелне,
Озайта, диләр бит, хәтта гомерне!

## АВЫЛДА ҖӘЙ

Авыл тынып калган. Көтү кайткан.
Түбә астына кергән малкайлар.
Берәм-сәрән качкан сыерларны
Эзләп алып кайта малайлар.

Сырткаена камчы эләксә дә,
Үч алмый ич сыер баладан –
Әнә, ничек йөгерә-атлый кайта,
Юньсезлеген гүя аңлаган.

Сөтбикәләр сөтен күптән биргән,
Мышный-мышный күшәп ял итә.

Әтәч белән таңнан торасы бар,
Аллы-гөлле болыннар көтә.

Сөтне күбрәк җыеп кайткан саен
Хуҗаларның йөзе ачыла.
Сөенә-сөенә, бер телем булса да,
Икмәк каптырырга ашыга.

Сыер җанлы авыл кешесе мин,
Сыйлы көнең – сыер, дигәннәр.
Сыерларга, хәтта, табынганнар –
Изге санап башлар игәннәр!..

## ГЕЛ ШУЛАЙ КӨТӘ СЫМАН

Кырын салып ак бүреген
Уйның татлысын сайлап,
Мәһабәт, горур гәүдәсен
Кузгатмак була җайлап.

Күп гомер көтеп килмәгәч,
Түземе җуелгандыр,
Күреп, сөйләшеп кайтыйм, дип
Сәфәргә җыенгандыр.

Тик ашыкмый, икеләнә,
Аймылыш булмабызмы?
Йөреп күрешү сәгатен
Озакка сузмабызмы?

...Дымлы керфеген болытлар
Иркәләп сөртә сыман.
Шулай сагынып Пушкинны
Кавказ гел көтә сыман.

## КЫШ

Күк гөмбәзе тишелгәнме,
Кар ява да кар ява.
Яр буйлары, тар тыкрыклар
Әйләнә мамык тауга.

Чал табигать үзе белә
Кайда таулар өяргә.
Тау шуган малай-кызларның
Аркасыннан сөяргә.

Кызык соң, шуа балалар
Чаналарга төялеп.
Әйдә, син дә, уйныйк бергә,
Рәхәтләнеп, кинәнеп.

Кемдер уйный «Кала баш»лы,
Кызганнан-кыза көрәш...
...И туган ягымның кышы,
Һәркемгә гайрәт өләш!..

## ШИФАЛЫ КӨЧ БАР БЕЗДӘ

Рәхим ит, түшәк түшәдек
Син төшәсе җирләргә.
Йомшак юрганга төрәбез,
Тимәс салкын җилләр дә.

Сый-хөрмәтебез җитәрлек,
Теләгәнеңне аша.
Шулай булмый, безнең халык
Бигрәк кунакчыл ласа.

Сыйлый-сыйлый үстерәбез
Ай үсәсен бер көндә.
Әйдә, үрлә югарыга,
Иркәләнеп иркендә.

Арышмы син, бодаймы син,
Шифабыз җитәр сезгә.
Келәтләргә сез кайтырсыз,
Өлгереп алтын көздә.

## АКЧАРЛАК

Көмеш канат акчарлак,
Очалар парлап-парлап
Язның бер мизгелендә
Зәңгәр күк киңлегендә!

Очалар парлап-парлап,
Агыйделкәйгә карап.
Агыйделкәй ак микән,
Эчәр суы пакь микән?

Акмыймы нефть, мазут,
Агуланмыймы азык?
Уйныйлармы балыклар? –
Балык булса, байлык бар.

Үзләренчә сөйләшеп,
Әллә инде киңәшеп,
Алдылар чумып-чумып,
Су өстен юнып-юнып.

Балыкның түмен татып,
Ихластан шатланышып,
Очтылар зәңгәр киңлеккә:
«Ирекә без, ирекә!!»

Көмеш канат акчарлак,
Очалар парлап-парлап,
Балаларын ияртеп,
Тормыш серен өйрәтеп...

Көзнең бер мизгелендә,
Агыйдел киңлегендә
Кошлар сәламен тыңла,
Мәрхәмәтле ак елга!..

## САБАНТУРГАЙ

Апрель башы. Сабантургай
Тизрәк кайтып та җиткән.
Кар беткәнен дә көтмәгән,
Өзелеп сагынды микән?

Күңелләрне дәртләндереп,
Сайрый да сарый тургай.
Игенчеләрне басуга
Чакыра-дәшә бугай.

Сандугачның тирәге бар,
Яратканы тал-тирәк.
Тургайның кайда тирәге? –
Аңа да бит ял кирәк.

Кунар тирәге икән ич
Кояшның ак нурлары!
Сайрасын гына тургаем
Яңгыратып кырларны –
Тыңлап һич тә туймамын!..

## МИН ДӘ АДӘМ БАЛАСЫ

Үзәккәйләрем өзелә,
Үтеп китсәң янымнан.
Мин дә адәм баласы бит –
Матурлыкка табынам.

Зифа буйларың килешле,
Бөгелеп, сыгылып тора.

Кочаклап бер үбәр идем,
Җитми кыюлык кына.

Артларыңнан йөгереп барам,
Борылып карарсың, дип.
Яндырмачы йөрәгемне,
Ялгызым каламын бит!..

## АККОШЫМ

Канат асларыңа алып,
Җылыт әле, аккошым.
Җаным кебек күрәм сине –
Мәхәббәтнең сакчысын.

Төреп ак мамыкларыңа
Назла әле, аккошым.
Сиңа әйтми, кемгә әйтим
Сүзләремнең татлысын.

Салып ак канатларыңа
Тирбәт әле, аккошым.
Сиңа гына бүләк итәм
Йөрәгемнең яртысын.

# АКЫЛЛЫ СЫЛУКАЙЛАР

*Балаларга*

Малайларга нәрсә кирәк?
Аналар назы кирәк,
Әтиләрнең җегәрлеге,
Акыллы сүзе – терәк.

## БЕРЕНЧЕ СЕНТЯБРЬ

Көзге кояшлы көндә –
Беренче сентябрьдә –
Алмаз бара мәктәпкә
Әтисе белән бергә.

Урам тулы укучы,
Дәртләнеп атлый бар да.
Нинди генә чәчәкләр
Ямь биреп бармый алда.

Алмаз да чәчәк тоткан,
Укытучысын котлар.
Бу күңелле бәйрәмне
Мәңге исендә тотар.

Тик дусты – эте Мөхтәр –
Әлегә берни белми.
Тик нәрсәдер сизенә,
Һич тә уйныйсы килми.

Мөхтәрнең дә эше бар:
Өйне саклар тырышып.
Абыйсы кайткач, уйнарлар
Йөгерешеп, куышып.

## АКЫЛЛЫ СЫЛУКАЙЛАР

Без булдыксыз малайлармы
Трай тибеп йөрергә?
Дус кызлар белән сөйләштек
Колыннар үстерергә.

Кушымта:
Колыннар, колынкайлар,
Акыллы сылукайлар.

Көн дә килеп малкайларны
Туйганчы ашатабыз.
Утарга чыгарабыз да
Зарядка ясатабыз.

Кушымта.

Койрык чәнчеп, кушаяклап,
Чапканнарын карагыз.
Үзебез дә кайчак кешнәп,
Ат-ат уйнап алабыз.

Кушымта.

Тараклар белән тарыйбыз
Ялтыратып өсләрен.
Алларында яшел печән,
Аңкып тора исләре.

Кушымта.

Тутырып күзгә карыйлар,
Ышанып, якын күреп.
Яратып үбәләр битне
Кайнар тыннарын өреп.

Кушымта.

Тай булгач та җәйләүләрдә
Чабып уйнарлар әле;
Мәктәп фермасын сагынып,
Кешнәп куярлар әле.

Кушымта.

# КЕЧКЕНӘ КЫЗ ГӨЛГЕНӘ

Йөгерә-йөгерә гөл үстерә
Кечкенә кыз Гөлгенә.
Кулларына лейка алып,
Сулар сибә гел генә.

Кушымта:
Гөлгенәнең гөлкәйләре
Яраттырмый кемнәрне.
Иркәләп, назлап, кадерләп
Тирбәтә таң җилләре.

Әнә ничек матур булып,
Күкрәп үсә гөлләре.
Гөлгенә белә торгандыр
Гөлләрнең дә телләрен.

Кушымта.

Йомшарткан да, утаган да
Гөлләренең төпләрен.
Лупа белән эзләсәң дә
Табалмассың чүпләрен.

Кушымта.

Бөрчек-бөрчек тирләр кунган
Гөлгенәнең йөзенә.
Гөлләр кебек чәчәк атар
Үсеп җиткәч, үзе дә!

Кушымта.

# АК КАЕН ЗАРЫ

“...Соңгы тапкыр кидем быел
Бу яшел күлмәгемне.
Кайчан да бер ишетерсез
Саргаеп үлгәнемне.

Ярата идем тормышны,
Җилләргә баш бирмәдем.
Җырлар җырлап, җирне ямьләп,
Зәңгәр күккә үрләдем.

Ботагымда ничә еллар
Кошлар бала чыгарды.
Җилдән саклап ояларын
Яфрак белән чорнадым.

Сандугачлар сөенә-сөенә
Кунып миңа җырлады.
Кешеләр, миңа сокланып,
Яңа җырлар чыгарды.

Шук малайлар килделәр дә
Күкрәгемне тиштеләр.
«Их, тәмле!» – дип, корытканчы
Ширбәтемне эчтеләр.

Мәрхәмәтсез шук малайлар
Белмәде кадеремне.
Мәхрүм иттеләр яшәүдән –
Яралап бәгыремне...”

...Яралы ак каенкайның
Моң-зарларын тыңладым.
Кызганып ачы язмышын
Үксеп-үксеп җыладым...
Шуңа моңсу җырларым!..

## УРАЗА ТОТАСЫҢ КИЛСӘ...

— Әнием, сәхәргә уят,
Ураза тотыйм әле.
Өйрәним дә, синең кебек,
Догалар укыйм әле.

— Уян, улым, торып юын,
Утыр өстәл янына.
Тамагыңны туйдырып ал,
Ашым кайнар, май гына.

— Әнием, ашыйсым килми,
Әллә иртә торганга.
Тәмләп кенә чәй эчим дә
Төренеп ятыйм юрганга.

— Чәй туйдырамыни, улым,
Җиңеләйтсә дә башны.
Ураза тотасың килсә,
Ипиләп аша ашны!..

## И, ШАМИЛ...

Кыңгыраулар шалтырады,
Дәресләргә кермисең,
Әллә, язма эш булганга,
Читтә качып йөрисең?

Кушымта:
И, Шамил, Шамил, Шамил,
Үз-үзенә ышанмый...

Дипломатыңны ач әле,
Бармы китап-кәгазең?
Никадәрле уенчыклар –
Кечкенә бер магазин!

Кушымта:
И, Шамил, Шамил, Шамил,
Уеннан һич бушамый...

Парта өстен тутыргансың
Төрле буяулар сылап.
Бу бит су эчкән коеңа
Була төкергән сымак.

Кушымта:
И, Шамил, Шамил, Шамил,
Мондый эшең ошамый!..

## САБЫР ТӨБЕ

— Әнкәем, алка алып бир,
Бер мин алкасыз калам...
— Сабыр төбе – сары алтын,
Сабыр итә күр, балам!

— Сабыр төбе тирәнме соң,
Төшә аламмы үзем?
Анда караңгы түгелме,
Төбен күрерме күзем?

Бакалар бакылдамыймы,
Еланнар ятмый микән?
Сабыр төбе шунда булса,
Хәзер үк төшеп китәм.

Сары алтынын алам да
Колакларыма тагам.
Мин дә бер чибәр кыз булыйм:
Тешне алтынга манам.

— Сабыр төбе – авыр хезмәт,
Кабаланма, күз алмам!..

## МОГҖИЗА

Ап–ак дәфтәр күзнең явын алып тора,
«Миңа яз да, миңа яз!» – дип балкып тора.
Гәүдәсен төз тотып бала тыйнак кына
Хәрефләрдән сүзләр ясый уйлап кына.

Нәкъ китапча һәрбер хәреф, – күрсәң әгәр! –
Хәреф түгел, тезгән гүя энҗе-гәүһәр.
Читкә чыкмый ич, каләме туры юлда,
Могҗиза – сүз хасил була тырыш кулда.

## ФӘРЕШТӘ

— Дәү әти, дим, дәү әти,
Кем була ул фәрештә?
Ашыймы, ашамыймы,
Эшлиме берәр эштә?

Юынамы, юынмыймы,
Коенамы ваннада?
Әти-әнисе бармы соң,
Фәрештәме алар да?

Машинада да йөриме,
Чаңгыда да шуамы?
Фәрештәләр укый торган
Мәктәпләр дә буламы?

Телевизор да карыймы?
Җырлар җырлап аламы?
Иртән мәктәпкә озатып,
Кызын үбеп каламы?

«Фәрештәм!» – дип, әтием ник
Эндәшә әниемә?
— Әйе, әниләр – фәрештә,
Белә шул әтиең дә!

## УЯН ИНДЕ ЙОКЫННАН!..

И, йомшак койрык кынам,
Уян инде йокыңнан.
Икәү бергә уйнарбыз, дип,
Сагынып кайттым укудан.

Сыйпармын башларыңнан,
Сыртыңнан, кашларыңнан, –
Бик иркәләнәсең килсә, –
Муеның асларыннан.

Биергә өйрәтермен,
Шигырьләр сөйләтермен.
Җырлап кына матур җыр
Алдымда тирбәтермен.

Матур күлмәк тегәрмен,
Ука белән чигәрмен.
Көзгегә кара әле,
Әнә, нинди чибәр син!..

Безгә килдең кайлардан? –
Тәпи астың кабарган.
Дәү әтиемнеке кебек,
Мыекларың агарган.

Песи, песи, пескәем,
Акыллым син, үскәнем!
Татлы йокыңа алданып,
Сизмисең көн үткәнен.

Күктә елмая кояш,
Дәртләнеп сайрый кошлар.
Куркытма син аларны,
Кошлар бит – безнең дуслар!

И, йомшак койрык кынам,
Уян инде йокыңнан.
Уянганың көтә-көтә
Рәсем ясап утырам...

## ЭЗЛӘП ТАПТЫК

Күршемнең эте югалган,
Түшендә ак йолдыз бар.

Күрмәдегезме, малайлар,
Күрмәдегезме, кызлар?

Акыллы, һөнәрле иде,
Кемнең дә күзе кызар.
Эзләшик әле, малайлар,
Эзләшик әле, кызлар?

Кайтып керсә, койрык болгап,
Ал аякларын сузар.
Тапмадыгызмы, малайлар,
Тапмадыгызмы, кызлар?
Дусты өчен җанын бирер,
Диңгезне йөзеп чыгар.
Шулай түгелме, малайлар,
Шулай түгелме, кызлар?

Ярый әле эзләп таптык,
Югалса, эчең сызар.
Рәхмәт сезгә, дус малайлар,
Рәхмәт сезгә, дус кызлар!..

## МАЛАЙЛАРГА НӘРСӘ КИРӘК?

Малайларга нәрсә кирәк?
Аналар назы кирәк.
Әтиләрнең җегәрлеге,
Акыллы сүзе – терәк.

Малайларга куәт кирәк,
Тимер-томыр, таш кирәк.
Мускулларны ныгытырга
Сагыз түгел, аш кирәк.

Штанга, чаңгы, гер кирәк,
Чүкеч, кадак... күп кирәк,
Трактор, машина, тулпар,
Очар өчен күк кирәк.

Батырлык, сабырлык кирәк,
Мең төрле һөнәр кирәк,
Туган-тумача, чын дуслар,
Дәртле моң-көйләр кирәк!..

## КӨЗ

Акланга кошлар җыелган,
Бүген туйлары бугай.
Көньякка китәр алдыннан
Бәйрәм итәләр шулай.

Сикерешеп, чыр-чу килеп,
Бииләр дә бииләр.
Шатлыклары хәттин ашкан,
Нишләргә дә белмиләр.

Балалары, зур кош булып,
Үсеп буйга җиткәннәр.
«Тыңларбыз, – дип, – ата-ананы!» –
Инде антлар иткәннәр.

Иртәгесен таңнан торып
Олы юлга чыгасы.
Һай, ерак барыр юллары,
Канатлары чыдасын!

Баш өстемдә канат кагып,
Саубуллаша кошларым.
Урман, сары яулык болгап,
Озата чын дусларын.

## ДӘФТӘР ЖЫЛЫЙ

Дәфтәр зарланып Фәһимнән
Үксеп җылый, кызганыч.
Ник җыламасын, күрегез:
Таланган һәм тузган ич!

— Җыерчык басты йөземне,
Таушалып беттем инде.
Тиктормас Фәһим кулында
Шул хәлгә төштем инде...

Ә малай шаркылдап көлә,
Авыз җиткән колакка:
— Дәфтәр дә булдымы соң мал,
Баш катырмыйм ул хакта!..

Самолет, көймә, этәчләр
Ясый дәфтәрне йолкып.
Кәгазь гармунда уйный ул
Бар дөньясын онытып.

Дәфтәр-кәгазь кадерен белә
Иптәшләрең, күр, Фәһим!
Сокландыгыч матур язалар,
Һәр битне саклап... Ә син?!.

## КҮРШЕЛӘРЕМ

Күршемдә матур кыз яши,
Исемнәрен — Оксана.
Ак күбәләкләр көнләшсен,
Бантигыңны таксана.

Йөзе якты, күңеле шат,
Булдыклы, уңган бала.
Ашыга-ашыга атлап
Көн дә мәктәпкә бара.

Көндәлегендә «бишле»ләр,
Әйтерсең, күктән яуган.
Юк, алар күктән яумаган,
Тырышып укып алган.

Энесе Коля исемле,
Ай-һай бик тере малай.
Ул да исәнләшә белә:
— Здравствуй, Ак бабай!..

## ТУГАН КӨН

Гүзәлнең иң истәлекле,
Бәхетле көне бүген.
Җыелып дуслары килде,
Хөрмәтләп туган көнен.

Икәүләп энисе белән
Әзерләнделәр алдан.
Өстәлдә җиләк сулары,
Алма, әфлисун, банан.

Тәлгәш-тәлгәш виноградлар,
Ашагыз өзеп-өзеп.
Пилмән дә пешеп өлгерде,
Кабарып, майда йөзеп.

Балланган тортның өстенә
«Гүзәлгә» дип язылган.
Шундый тәмле! – күрү белән
Сулар акты авыздан.

Һәркем оста икән монда:
Алдылар җырлап, биеп.
Музыка яңгырап торды,
Күңелләргә дәрт биреп.

Сизелми дә үтте бәйрәм,
Бергәләп уйнап, көлеп.
«Үскәнем!» – диеп энисе
Гүзәлне алды үбеп.

## ӨЙРӘНӘБЕЗ ТУГАН ЯКЛАРНЫ

Рюкзакларны асып аркабызга
Сәяхәткә чыктык бергәләп.
Күңелләргә чиксез шатлык биреп,
Кояш көлә безне иркәләп.

Кушымта:
Уйнасын быргы,
Уянсын кырлар.
Әйдәгез, җырлыйк,
Егетләр, кызлар!

Җырлар җырлап, урман-кырлар буйлап,
Нинди рәхәт аяк атлавы.
Әтиләр эшенә гашыйк булып,
Өйрәнәбез туган якларны.

Кушымта.

Салаватлар үткән бу юллардан,
Җиргә тамган изге каннары.
Килер буыннарга илһам биреп,
Маяк булып балкый даннары.

Кушымта.

## АКТҮШ

— Актүш, Актүш!
Кил яныма,
Кая китеп югалдың?
Миннән качып, йә, әйт әле,
Кемнәр белән уйнадың?

Беләсең бит абзарымда
Сыер, сарыкларым бар.
Казларым йөри каңгылдап,
Елгыр тавыкларым бар.

Мин малларны караганчы
Читкә чыгып тайгансың.
Тоттырмас чыпчыкны куып
Әлсерәгән – аргансың...

Рөхсәтсез-нисез хуҗаңны
Ташлап китүең хата.
Гел үзең өчен яшәмә,
Башкалар хакын хакла.

— Актүш, Актүш!
Коштай очып,
Актүшем җитте килеп.
Койрыгын ул болгап алды:
"Гафу ит!" – дигән кебек.

## АЙ ҮСӘСЕН БЕР КӨНДӘ ҮС...

Ишетегез, кызым туды,
Чәчәгем, асыл гөлем,
Шатлан, бәхетле күңел!
Йоклый бит ул изрәп кенә,
Елый икән,әзрәк кенә,
Көйләве берни түгел.

Әннәсе дә, әттәсе дә,
Дәү әнкәсе – барсы да:
"Юатыйм!" – дип ашыга.
Уенчыклар, йөгереп кенә,
Уйнап, биеп, сикереп кенә,
Килә кызым каршына.

Ул курчаклар, каз, үрдәкләр
Берсеннән-берсе чибәр,
Уфадан килгән, диләр.
Күз алмама бүләк итеп,
Җөйсез юрган, күлмәк тегеп,
Мәскәүдән җибәрделәр.

Белмим, кайчан өлгергәннәр
Казанлылар ишетеп,
Кызыбызны иш итеп.
Посылкада ни генә юк:
Башлыклар, пинетка, туп,
Хәтта каюлы читек.

Кызыма тел чыкмаса да,
Үземнән өлкән ирләр:
— Ничек сөйләшә! – диләр. –
Картайсак та: "Яшь бабай!" – дип,
Безне яшәртеп җибәр.
Сөенсен иш күңелләр!

Ай үсәсен бер көндә үс,
Минутлап артсын синдә көч,
Гомерең булсын озын.
Башкортстан кочагында,
Нурланып Ил кояшында
Үс, күз алмам, йолдызым!

## КЫЗЫМ ИЛМИРАГА

Гүзәлләрнең гүзәле син,
Тормышымның бизәге син,
Бар дөньямны нурлы иткән
Мәхәббәтнең үзәге син!

## ГАРМУН УЙНЫЙ КЫЗ БАЛА

Көмеш тавышлар яңгырый,
Гармун уйный кыз бала.
Басмасына катырак бас,
Бармакларың кызганма!

Су буйлап ерак тарала
Гармуныңның моңнары.
Абыең да уйнар иде,
Булса әгәр куллары.

Кайтты абыең сугыштан,
Гармунчы ул тумыштан.
Керфегендә яшь бөртеге,
Күңелләре тулышкан.

Чечняда кулы өзелгәч,
Абыең калган һушсыз.
Төшләрендә гармун уйный,
Яши алмый ул шунсыз.

Һәр эшнең үз вакыты бар,
Өйрән яшь көннәреңдә.
Тылсымлы көчләр бар бит ул
Гармунның телләрендә.

Тартып, сузып уйна, сеңлем,
Чәчәкле күрекләрен.
Күңелләрен күтәр әле
Ветеран егетләрнең!

## ЙӨЗЕК КАШЫ

— Асрамага бала бирәм,
Бала бирәм, кем ала?!
Печән базарында ямщик
Ялвара, сөрән сала.

— Асрамага бала бирәм,
Ягымлы, тыйнак бала,
Акыллы, зирәк бала,
Бала бирәм, кем ала?!

Ямщикның күңеле йомшак,
Күзләренә яшь килә.
Базарда бала сатуы
Саваплы бер эш, димә.

Алырлармы, алмаслармы,
Кем кулына эләгер,

Сабыйның килер язмышын
Алла гына беләдер...

— Ник язам бу таныш хәлне? –
Сорау бирәм үземә,
Искә төшеп, йөрәк әрни,
Үзәкләрем өзелә.

Ярый әле, мәрхәмәтле
Җаннар булган татарда,
Явыз үлем тырнагыннан –
Газраилдән сакларга!

Тудырып халкым Апушны
Сөекле шагыйрь итте.
Тукай – ул милләтем күрке,
Күңеле, бавыр ите.

Укыган саен китабын
Яшәрәм, хисләр ташый.
Ул – татарның сандугачы,
Аклыгы, йөзек кашы!..

## МАЛАЙЛАР

Кырык бердә этиләре
Киттеләр ерак.
Кыен булса да малайлар
Калмады елап.

Ил язмышы хәл ителә
Фронтта, тылда.
Ару-талу белмәс уллар
Һәрвакыт юлда.

...Йөгән тотып арба өстендә
Малайлар ята.
Әкрен генә төн авыша,
Сызылып таң ата.

Бригадирның аяк тавышын
Ишетә бар да.
Күзләреннән йокы кача, –
Командир янда.

Фронттан кайткан командир,
Әйт, ничек түзгән?! –
Снаряд ярчыгы тиеп,
Аягын өзгән.

Күр, Кызыл Йолдыз орденын –
Гүя, ут-ялкын!
Медальләре чың-чың итеп,
Нурланып балкый.

Боерык нинди булса да
Үтәлер тәгәл.
Үгез башына малайлар
Кидерә йөгән.

— Беззз, беззз! – килеп куа алар
Пар тоякларны.
Иген игүдән дә изге,
Күркәм эш бармы?!

Әтиләр исән кайтсыннар,
Тулпарлар кайтсын.
Әтиләр җиңеп кайтсыннар,
Тик хәзер чап син!..

Малайлар теләген аңлап,
Малкайлар чаба
Җиңү язын якынайткан
Таңнарга таба...

## ВЕТЕРАН КОСТЮМЫН КИЯ

Ветеран костюмын кия,
Кешелеккә дигәнен.

Беркайчан да онытмый ул
Бәйрәм җитеп килгәнен.

Күзге каршысына басып,
Йөзенә карап тора,
Яугир яшьлеген сагынып,
Мыегын бора-бора.

Дәү әтисенең алдына
Менеп утыра сабый.
Инде ничә тапкыр аның
Орден, медален саный.

Асыл тавышлар чыгарып,
Көмеш тәңкәләр чыңлый.
Колагын якын китереп,
Тәңкәләр җырын тыңлый:

— Безне – орден, медальләрне –
Алды батырлык өчен.
Фашистлар белән алышта
Күрсәтте ул бар көчен!

Берлинга барып җитте ул
Дошманны кыра-кыра,
Тыныч тормышта яшәргә
Планнар кора-кора.

Күкрәгендә чыңлый-чыңлый
Яшибез горурланып.
Тиңсез гүзәл эшләренә
Сокланып, хозурланып.

...Ветеран костюмын кия –
Кешелеккә дигәнен.
Бүләк итте оныгына
“За отвагу“ медален!..

# *ОЧЫ БЕР ЧЫГА*

**Юмор һәм сатира**

Нәфесе азган кешеләр
Күбәеп китте бигрәк.
Без капчыкта ятмый, диләр,
Очы бер чыга, димәк!..

## ШУНДА МӘХШӘР ВӘ ТӘМУГЪ

Мәрмәрдән сарайлар салды,
Шактый мая туплагач.
Халыкның кесәсе белән
Үз кесәсен бутагач.

Машиналар гынамы соң?! –
Самолет алды сатып!..
Үзе теләгән илләргә
Йөри ул барып, кайтып.

Яшьлеге әйләнеп кайтты,
Яшь хатын алып килгәч.
Ышанган юха теленә,
Майда йөздерәм, дигәч.

Әшнәләре ярдәм иткәч,
Җибәрде завод салып.
"Яшел елан" концерт куя,
Шунда мәхшәр вә тәмугъ.

Типтерәләр, сиптерәләр,
Байларга юллар ачык...
...Бушка эшләгән халыкка
Кычкырып килә ачлык.

## РЕФОРМА

Реформа буксовать итә,
Итә дә артка китә.
Аркалар чиләнеп бетә
Тырышып этә-этә.

Түрәләр алганнар сырып,
Күкрәген киереп тора.
— Алай итмә, болай ит! – дип
Боерык биреп тора.

— Пешкәнсең, сөрт тиреңне! – дип,
Укучым сөлге суза,
Алга да юк, артка да юк,
Таптанып гомер уза.

Моторы юньләп эшләми,
Бер сүнә, бер кабына.
Чыгып җиткәч, төртеләбез
Волокита тавына.

## ХӘЙЛӘЛӘ

Ташкын булып халык чыккан
Урамга.
Ничәмә төрле әләмнәр
Урала.

Фикрең булмаса да кычкыр,
Нотык тот.
Җиде барабан тетмәсен
Тетеп чык.

Үзеңне онытма, макта,
Хәйләлә!..
Алдасаң да... Җир барыбер
Әйләнә...

## "ЗАПАРАЙ"НЫ РЕМОНТЛАГАНДА

Машиналар ялт-йолт кына
Ремонттан чыгып тора.
Яугир Әптерәйнең менә
Өмете сынып тора.

Әнә аның "Запарае"
Чиратта, тик иң артта.
Гүя монда машиналар
Төзелгәннәр парадка.

Соң килсә дә һаман алга
Ертышып керә "Лада".
Ни пычагыма тыгыла,
Урын юк ласа анда!

Кызмаса да кызар каның! –
Түбәнсетсәләр шулай.
Әптерәй абзаң кемнән ким? –
Мыскыл итмәгез болай.

Хаксызлык, гаделсезлекләргә
Торырмы ир баш биреп?
Нәрсә әйтерләр, ул китсә
Туп-туры цехка кереп?

Борын төбендә шап итеп,
Ябылыр тимер капка.
Ишетмәгәнен ишетеп,
Көлкегә кал нахакка!

Вакыт үтә, чират җитми,
Нишләсен, көтә һаман.
Әллә кайтып китсен микән?
Чакыртырлар берзаман.

Кайтса, хәләл җефетеннән
Ишетерме җылы сүз?
Колак итен кимерсә дә,
Сызланма, дус, чыда, түз!

— Син җебегән, булдыксыз! –
Карчыгы агу чәчәр.
Бер сүз әйтеп булмый инде,
Үрә торса да чәчләр.

Ничә айлар үтте инде,
«Запарай» шунда һаман.
Күңеле булыр иде дә
Эндәшмәүләре яман.

Тик «лимон» күрсәткеч кенә
Телгә килде түрәләр.
Әптерәйнең «Запарае»
Тиздән цехка үрмәләр!..

## ПЕШӘ ТОРА...

Пешә тора сүз боткасы,
Үзеңне-үзең мактау.
Эчне пошыргыч шапырыну
Һәм гаепләне аклау.

Нинди генә сүз юк хәзер
Әйләнешкә кермәгән.
Ул сүзләр тел сындырырлык,
Ишетмәгән, белмәгән.

## НӘФЕС

Атым ургә менә алмый,
Тиргә батты, бахырым.
Нәфсемә булышкан булып,
Төягәнмен артыгын.

Печәне җиләк кенә шул,
Чәйгә салып эчәрлек...
Әйдә, малкай, кузгала күр,
Тарт тагын бер көчәнеп!

Булышыйм әле үзем дә,
Миндә дә көч җитәрлек.
Карасана, хәлем бетә –
Кая киткән җегәрлек?

Тәмам ачуым кабарды,
Сыртына салып алам.
Тик йөк һаман бер урында –
Кузгалырмы берзаман?

Тәрткәләп корсак астына,
Тарткалыйм авызлыгын.
Әкрен-әкрен ат чигенә,
Куркытты явызлыгым.

Йөгем ауды, тәртәм сынды,
Бичаракай буылды.
Түшлек бавын кискәч кенә
Үлемнән ат котылды.

* * *

...Рюмка алгач та кулыма,
Искә төшә мескен ат.
«Төямимме артыгын?» – дип,
Сорау бирәм ничә кат.

## БЕР ЕГЕТ

Мичәп җикте тулпарларны
Бер егет.
Әйләнеп кайтмакчы булып,
Җил җилеп.
Утырган төренеп үзе
Толыпка.
Камчысы белән атларны
«Җылыта».
Төпкә җигелгәне баткан
Күбеккә.
Нәкъ шунысы тартмаган күк
Егеткә.

Камчысы белән суктыра
Ничә кат.
Ишетмәгәнен ишетә
Мескен ат.
Уйнаклап, ян-яктан чаба
Юртаклар.
Уртаклашмый авыр йөкне
Ул атлар.
* * *
...Түрәнең чыкса ачуы
Кемгәдер,
Беләм: аңа ат язмышы
Эләгер.

## КӨТӘЛӘР

Комбайнерлар җыелышып
Утыралар чүмәләдә.
Каршыларына агроном
Җайлап кына чүгәләгән.

Тәмәке суыра-суыра
Әзмәвер ирләр сөйләшә:
— Кыздыра Кояш, кыздыра,
Начар – яңгырга көйләсә!..

Агроном Сафа кушыла
Төтен алка ата-ата:
— Безнең бәхет җиңә, дуслар,
Игеннәрне җыйган чакта.

Ашлыкны җыеп алырбыз,
Калдырмабыз бөртеген дә.
Белмим икмәк-тоздан башка
Яшәгәнен беркемнең дә.

Язлар гына җайсыз килә,
Чәчүләре үтә авыр.
Теңкәләргә тиеп бетә
Кырыс җилләр, карлы яңгыр.

Тора да арадан кемдер
Комбайн астына керә:
— Күләгәдә яхшырак, – ди. –
Черем итеп алыйк бергә!

Бригадир Мөслим йөткерә:
— Покослар шытырдап кибә.
Җыеп алырбыз тиз көндә,
Безнең кулдан бар да килә!

Машинада аш китерә
Комбайнерларга Мәчтүрә:
— Кайда сез эшләгән җирләр? –
Кулын куйган каш өстенә.

— Чык кипкәнен көтәбез, – ди
Бригадир да, агроном да...
— Оят түгелме? – ди түти, –
Белмисез төш ауганын да!

## ҖӘП СӨРГӘНДӘ

Тракторчы Фәтхелислам
Җәп сөрә безнең басуда.
Кабинада кырын төшкән,
Тәмәке көйри авызда.

Йөгерә-чаба трактор,
Яктан-якка уйный сабан.
Кылгый-былгый буразналар
Бөгәрләнгән елан сыман...

Фәхелислам китте айнып,
Тәмәкесен бәрде атып:
— Җирне әрәм иткәнсең! – дип,
Агроном кыз сузгач акт...

## ТӨТЕН

Морҗа башыннан чыга да,
Үрмәли югарыга.

“Кысык мичтән котылдым!” – дип,
Тотына куанырга.

Җил кайдан, төтен шул якка,
Бөтерелә, болгана.
Теләсә, теләмәсә дә,
Күз алдыннан югала.

Төрле төсләргә керә дә,
Мактанган була төтен:
— Утынга янарга куштым
Мин бит барысыннан өстен!..

## КҮЗЕҢ ТӨШТЕМЕ ӘЛЛӘ?

Тигәнәк түгелсеңдер,
Күләгә түгелсеңдер.
Белмим, ник минем артымнан,
Белмим, ник минем артымнан
Тагылып йөрисеңдер.

Күзләреңне текәмә,
Тимә, зинһар, теңкәмә.
— Сине генә яратам! – дип,
Сине генә яратам! – дип,
Китче, миңа сөйкәлмә!

Күзең төштеме әллә?
Кыйблаң күчтеме әллә?
Мин бит, энем, ир хатыны,
Мин бит, энем, ир хатыны,
Кызлар беттеме әллә?

## ӘТИ БУЛДЫМ МИН БҮГЕН!..

Әнинең йөзе кырыс:
— Сиңа, улым, зур бурыч:
Я легковой, я ат тап,
Хәзер үк әйләнеп кайт.
Юкса эшләр харап, ди,
Сөендер, ди, ярабби.

Катып торма, тизрәк, ди,
Транспорт кирәк, ди.
Юлларың уң кылсын, ди,
Бәхете белән тусын, ди...
...Әйләнеп китте башым,
Эшне нәрсәдән башлыйм?
Хәл-әхвәлен сорыйммы?
Берәр дару сузыйммы?
И, сөекле хатыным,
Түз инде, түз, алтыным!
Идарәгә барыйммы,
Фермадан ат алыйммы?
Шалтыратсам әгәр дә
Теге «Ашыгыч ярдәм»гә?
Әни әйтә: Пешмәгән,
Үз башыңа төшмәгән.
Карасаң үзең татып,
Тормас идең шаккатып.
Күз ачып йомганчы кайт,
Я легковой, я ат тап!
Беттем тәмам чуалып,
Нәкъ ятьмәдәге балык!
Нишләргә белми торам,
Үземчә план корам:
Барсам әгәр фермага,
Калмагандыр бер мал да.
Рәиснең легковоен
Сорыйм, бирер, мөгаен...
Легковой түгел, бер ат
Җигеп кайттым менә, вәт.
Мендәрләр сала-сала
Әнкәй укынып ала:
— Рәхмәтең кыл, Ходаем,
Җиңеллек бир һәрдаим.
Кара аны, улыкаем,
Изге булсын юлкаең.
Килен сабыр, акыллы,
Туктатма, ку атыңны!
Ничек итсәм дә иттем,

Роддомга барып җиттем.
Каршы алдылар бар да:
Сестра-докторлар да!
Йөрәк кага, башым ут,
Елга тора бер минут!
"Әттәү!" – дип туды балам,
Йөгереп тә китте аннан.
Шатлыктан балкый күгем –
Әти булдым мин бүген!

## МАШИНАЛАР КИТТЕ ГӨЖЛӘП

1.
Хуҗа кеше башын вата:
— Нигә безнең колхоз артта?
Эшләр харап – болай барса,
Тавыкларның саны арта.
Комбикорма, веткорманы
Башка маллар ашар аны.
Тавыкмы доход бирер кош?
Игелек көтсәң, чыгар «чыш-пыш».
Кытайныкылар молодец,
Берсе өчне салган, ди ич.
Америка исән булсын,
Боты белән базар тулсын.
Зоотехник Габделгата
Кыяр-кыймыйча сүз ката:
— Аңлый алмыйм, Садыйк абзый,
Кош буенча колхоз аксый...
— Олы кешене тыңла син,
«Кызыл маяк»та хуҗа – мин!
Көненә бер күкәй салган
Тавыкны асрар надан!
Артталык сәбәбе – тавык!
Котылу әмәлен табыйк.
...Иртәгәсен ферма тузды,
Тавык белән кузов тулды.
— Машиналар китте гөжләп –
...Ит комбинатына төбәп...

2.
Эшләр харап – болай барса,
Сарыклардан үрчем арта.
— Мең сарыктан – өч мең сарык,
Кая китә бөтен байлык!
Күпме печән, салам кирәк?
Файдасыннан зарар күбрәк.
Бәрәннәр – песи зурлыгы,
Ит, йон кот, адәм хурлыгы!
Йон, тиресен булмый сатып,
Клиент эзләп үтә вакыт.
Зоотехник Габделгата
Рәис Садыйкка сүз ката:
— Өч мең түгел, биш мең булсын,
Бәрәкәттән кем соң туйсын?
— Олы кешене тыңла син,
Хәреф ятлаучы булма син.
Бәрәкәт түгел, мәшәкать! –
Бетәбез, болай яшәсәк!
Өстәл төеп алды Садыйк:
— Тәкә алыйк, вот ул байлык!
Үрчеми дә, аз да ашый,
Биш кило йон бирә башы.
Иртәгәсен ферма тузды,
Сарык белән кузов тулды.
Машиналар китте гөжләп –
Ит комбинатына төбәп...
3.
Атларның баш саны арта,
Эшләр харап – болай барса:
— Чутсыз азык китә икән,
Кыскартырга булмый микән?
Искелек калдыгы ул ат,
Безнең чорга хәтта бик ят!
Нәрсә эшлибез соң җигеп,
Керем бармы бер тиенлек?
Зоотехник Габделгата
Рәис Садыйкка сүз ката:
— Атсыз әле яшәп булмый,

Нәселен корытып куймыйк...
— Олы кешене тыңла син!
Әйдә, алашалар калсын,
Юк-бар йомышларга барсын...
Иртәгесен ферма туздаы,
Атлар белән кузов тулды,
Машиналар китте гөжләп –
Ит комбинатына төбәп.
4.
Хуҗа һаман башын вата:
— Нигә колхоз һаман артта?
Көч җитәр эш караштырыйк,
Вывесканы алмаштырыйк.
Таратыйк колхоз малларын,
Китсен трактор, комбайн.
Җирне бүлеп бирик пайлап,
Колхозчыны җайлап, майлап.
Кем үз көнен үзе күрер,
Иркенлектә гомер сөрер;
Кем юкагачка атланыр,
Атлылар да атсыз калыр...
***
...Таралгач колхоз маллары,
Түрәләргә эш калмады...

## МУТЛЫК

Койрык очына бер тамчы яңгыр тамсын,
Кәҗә халкы оныта икән бар дөньясын

Көтүченең янауларын ишетми дә,
Элдерә ышык урынга – иш итми лә...

## ДОЛЛАР

Безнең акча – акчамыни? –
Олтырагы долларның!
Шул доллар кимерә инде
Илебезнең малларын.

Долларың булса, син – түрә,
Абруйлы, сүзең өстен.
Юк икән, син – кирәксез зат,
Бер бөҗәк җирдә, мескен.

Ялкаулыкта гаепләнеп,
Исем күтәрә халкым.
Эш табалмый җәфа чигә,
Булса да кулы алтын.

## ОНЫТКАН

Үтәр хәл юк: кара борының
Капка астыннан сузып,
Һау–һаулап, өреп каласың,
Тынычлыгымны бозып.

Көчек чагыңнан ук беләм,
Сый-хөрмәт итә идем.
Күзгә карап, койрык болгап,
Күчтәнәч көтә идең.

Беркайчан да рәнҗетмәдем,
Аштан мәхрүм итмәдем.
Каршы алдың, озата бардың,
Сиздем – булдым көткәнең!

Аякларыма уралып,
Әйтче, күпме уйнадың?
Ай-һай, юха идең мәгәр –
Нигә песи булмадың?

Хәзер гауга куптарасың –
Хуҗаң шулай кушамы?
Син кем булып чыгасың соң,
Аумакаймы, куштанмы?

Кичә нигә таягымны
Чүбекләндердең чәйнәп?

Валлаһи, үтерә идең,
Калмасам алдан шәйләп.

Ул күзләрең кып-кызыл кан,
Тешләрең кылыч кына.
Гаебем булса, әйтсәнә,
Аңлашыйк тыныч кына.

Күрәм: буең үстергәнсең,
Симерүең дә җиткән.
Димәк, хуҗаң хәстәрлекле,
Өзми колбаса, иттән.

Мөгаен, легковойларда
Җилдерәсеңдер әле.
Шашлык ашап, сөякләрне
Кимерәсеңдер әле.

Кешеләргә гаҗәпләнмим —
Дусларын тиз оныта.
Шунысы гаҗәп, оныткансың,
Эт тикле эт булып та!

## СӘРХҮШ

Төн урталарында килеп,
Шакып ишек ачтырды.
— Үләм, башым ярыла! – дип,
Утка, суга бастырды.

Йокы аралаш нитмәк кирәк,
Төштем тәмам коелып.
Бертуктаусыз җикеренә,
Тормый бит һич тыелып.

Хатын әйтә:
— Цитромон да,
Аспирин да бар безнең
Шунда, комод тартмасында,
Даруларны ал үзең!..

Йөрәге тора җилфердәп
Усак яфрагы кебек.
Ауный, тәгәри идәндә,
Борыны беткән җебеп.

— Төкеренмә, дим, тынычлан,
Өстең-башың карала.
Ярдәм бирсен хатының
Исрек ирне карарга.

Хатын әйтә:
— Чәй ясадым,
Чәй эч, башың төзәлер!
— Үзең эч! – дип кырт кисте бу,
Кем дип үзен беләдер.

Алмады даруларымны,
Эчмәде чәйне, түкте.
— Төлке! – дип, – Саран шайтан! –дип,
Җитмәсә, безне сүкте...

## ҖАЕН ТАПКАН

Печән йөге кебек төяп
Кайтты Хатип утыннан.
Кай арада ир-ат кереп,
Йөк сүтәргә тотынган.

Шундый матур гадәт һаман
Яши әле авылда.
(Әйтсәм әйтим, берән-сәрән
Ялкаулар да табыла).

— Ай-һай, утынның хәтәрен
Алып кайткансың! – диләр.
— Каравылчының, мөгаен,
Җаен тапкансың! – диләр.

Хатипның авызы ерык,
Канәгать үз эшеннән.
Шулай булмый, авыр йөкне
Җилкәсеннән төшергән.

— Билетың булсын мөһерле,
Торсын анда ун тамга,
Башбаштакланып барыбер
Керәлмисең урманга.

Дөрес, аның коймасы да,
Тимер капкасы да юк,
Каравылчының билендә
Патрон тасмасы да юк.

Әмма ләкин һич тә аның
Авызы кыек түгел.
Күпме бирсәң дә күтәрә,
Буыны сыек түгел.

Яланның олысы хәтле,
Күңеле иркен аның.
"Ак баш"ны күрдеме, энем,
Бирә дә бирә... җанын!

Утынның ниндие кирәк:
Ак каенмы, усакмы?
Сайлап ек та агачларны,
Бер читкә ат ботакны.

Шәм кебек чыршыны аудар,
Утырмасын әрәмгә.
Бар да кирәк үз йортында
Дөнья көткән адәмгә.

Саранланма, йоттырып ал
Шайтан түкергән суны.
Документыңа кул куйдыр,
Уңайла кайтыр юлны.

...Шаккатып тыңлаган була
Күпне күргән ир-атлар...
Беләм, каравылчы өчен
Һәр йорт "күчтәнәч" саклар!..

## НЛО

(Шаяру)
Каһәрең, көн кыска булгач,
Киттем төнлә мунчага.
Ләүкәдән чабынып төштем,
Кулда сабын, мунчала.
Бервакыт ишек ачылды:
— Мөнәвәрә, синме бу?!
Ул да, ул да түгел кебек,
Кешеме, таш сынмы бу?
Өстендә ал комбинезон,
Башында модный шлем.
Чалбарымны кияр идем,
Кузгалыр хәл юк – нишлим?
Туп-туры өстемә килә:
— Курыкма, син тыңла, – ди –
Җине эзләп күктән төштем,
Тегеннән мин, НЛО! – ди.
Күзем маңгаема менде,
Кычкырам – чыкмый өнем.
Бар икән күрәселәрем,
Әйләнмәс булды телем.
— Оялчан булып кыланма,
Чишендер, – ди, – тиз генә.
Иркәләнәсем килә, – ди...
... Күңелем нидер сизенә.
Вәт әкәмәт: хатын ич бу!
Миңеннән танып алдым.
Замана юләрләнә, дип,
Юләрләнмикче, җаным!

## АШХАНӘДӘ

Йомыш төшеп сирәк-мирәк
Калага баргалыйбыз.
Базардан базарга чабып
Әйберләр алгалыйбыз.

Кырылып яткач кырык эшең
Авылга ашыгабыз:
— Исәнмесез, мал-туарлар,
Без кайттык, каршылагыз!

Бер килгәндә бик ачыгып
Ашханәгә юл тоттык.
Тәмле ашлар ашыйк әле,
Мәшәкатьне онытып.

Әнә нинди бит заллары! –
Ашлары кайнап тора.
Йомшак кәнәфиләренә
Утырдык җайлап кына.

Йөрәк-бәгырьне эретеп,
Агыла моңлы көйләр.
Ишетсә: "Нәкъ безнеңчә!" – дип,
Тукай рухланып сөйләр.

Өстәл тулы затлы ризык,
Ник күңел үсмәсен, ди.
Җиңгәң әйтә: "Кабаланма,
Авызың пешмәсен", – ди.

Өф-өф итеп, өреп ашка,
Каптым кашык тутырып.
Нинди хикмәт: йоткылыкта
Телем калды утырып.

Җиңгәң актара авызны,
Алҗыгач үзем тәмам:
— И юләр, телен йоткан бит,
Чыкмый да чыкмый һаман.

Дәрестә ничек сөйләрсең? –
Син бит әле тарихчы!
Монда утырмыйк булышып,
Больницага барыйкчы!..

Пешекче дә килеп җитте,
Сөйкемле бала икән.
Авылдан килгәннәр кайчак
Югалып кала икән.

Барысы да җиткелекле:
Борычлары, тозлары.
Тел йотарлык аш пешерә
Безнең якның кызлары.

## ГАЛИУЛЛА - МӨДИР БЕЗДӘ

(фельетон)
Галиулла – мөдир бездә,
Ашлык амбарына хуҗа.
Тәмәкесен суыра-суыра
Уйлар дәрьясына чума.

Дөньяда икмәктән арзан
Нәрсәнең булуы мөмкин?
Өстәлеңдә ул булмаса,
Өй караңгы, хәлең мөшкел.

Иң кадерле нәрсә – икмәк,
Икмәк алдында баш иям.
“Икмәк булса, җыр да була!“ –
Кем шулай әйткәнен беләм.

Нитмәк кирәк, кумак-тычкан
Амбарыңны тишеп ятса,
Шул тишектән алтын бодай
Ком шикелле ишелеп акса,

Яки түбә черегән булып,
Яңгыр суы торса тамып,

Яки кипмәгән ашлыклар
Күмерләнсә утсыз янып...

Галиулла белә моны,
Галиулла – төпле хуҗа,
Сәбәпне күп табып була
Амбардагы югалтуга.

Җаен табып ара-тирә
Таныш-белеш килеп тора.
Грузовойлар, легковойлар
Капчык салып китеп тора.

Кунак ашы – кара-каршы,
Кем калыр бурычлы булып,
Стаканнар бер-бер артлы
Ава мөлдерәмә тулып.

Төшке ашка кайта алмый,
Тынгысыз эш – мөдир эше.
Эңгер-меңгер төшкәч кенә
Кайтарып куя дус-ише.

Үзен-үзе белештерми,
Идәнгә бәрә маңгаен,
Хатынының чәчен йолка,
Юләрләнгәнме, Ходаем?!

Башын куяр урын тапмый,
Болындай булса да өе.
Хатынының кунар җире –
Күршесенең ишек төбе.

Ревизорлар күренгәнче
Кирәк бер әмәл табарга.
Әллә капкыннар куйсынмы
Күсе азды, дип, амбарда?..

* * *

...Өлгермәде Галиулла,
Яңа амбар пломбаланган.
Үзе таш капкынга капкан,
Белмим, кайчан чыгар аннан?

## ОЧЫ БЕР ЧЫГА, ДИМӘК...

Уйларың чуалган чакта
Кашып ал газиз башың.
Күз алларыңда нур уйнар,
Үтәр ашаган ашың.
Саннар үзең теләгәнчә
Утырыр урынына.
Дөньяда күпмени алар,
Бердән башлап ун гына.
Керемне кем санап торсын,
Сал кесәңә затлысын.
Акча инде иң затлысы! –
Аннан шәбен тапмыйсың.
Кесәләрең күп булса да,
Берсендә генә сакла,
Саклык кассасы ул кесәң,
Акыллы башлар тапкан.
Чыгымны чынлап санарлар,
Чыгымыңны дәлиллә,
Кыш урын тапмасаң әгәр,
Башка фасыл бар җирдә!
Чыгымың агызып язын
Гөрләвекләр агар.
Җәен, кыздырып алыр да,
Шыбырдап яңгыр явар.
Бер чылатыр, бер туңдырыр
Көз айлары – көт тә тор!
Ялган документлар теркә
Һәм списать итә тор!
“Киңәшләр ялгыштырмас“, – ди
Сафиулла бухгалтер:
“Ишле булмасын дусларың,
Ишлеләр сүз болгатыр“.

* * *

...Нәфесе азган кешеләр
Кубәеп китте бигрәк.
Без капчыкта ятмый, диләр,
Очы бер чыга, димәк!..

## БАР БИТ УЛ...

(Тукайча ук булмаса да)

Банкет залларында тамак
"Чылатулар" бар бит ул.

Салып алган егетләрнең
Януларьı бар бит ул.

Урманда, елга буенда
Җыелулар бар бит ул,

Асыл ярлар кочагында
Җылынулар бар бит ул.

Баш авырткач, өстәл сугып,
"Эш кылулар" бар бит ул.

Ятлар блән курортларга
Ычкынулар бар бит ул.

...Килеп капкач, Шүрәледәй,
Кычкырулар бар бит ул!...

## ӨЙЛӘНДЕМ

Өйләндем тагын бер кызга,
Яратып, сөеп кенә.
Әниемә дә ошады
Күреште көлеп кенә.

Кушымта:
И әни, әни, әни,
Бирер идем әлләни!..

Беренчесен, тарткан өчен,
Кертмәде ул ишектән.
Икенчесен өнәмәде,
«Авырлы!» – дип ишеткән.

Кушымта:
И әни, әни, әни,
Минем йөрәгем әрни!..

Матур да инде сөйгәнем,
Чәчләре, күз-кашлары.
Үзебезчә, нәкъ татарча,
Сукалый да башлады.

Кушымта:
Их, әни, әни, әни,
Сөйләшүе әлләни!..

## ЯРАТАМ

Хатыныма да кагылды
Демократия җиле.
Авызында сигареты,
Бар дип тә белми мине.

Эштән кайта "Мерседес"та,
"Под градусом" инде.
Ничек аш-су әзерләсен,
Керемне юсын инде.

Иренемне тешләп түзәм,
Югалтмый акылымны.
Этле-мәчеле торсак та,
Яратам хатынымны!

## ГАЗРАИЛ

Ашыгып килеп тә җиткән,
Көтмәгән чакырганны.
Әллә алдында, мах биреп,
Сузылып ятыргамы?

Хәлләрен белеп чыгыйм, дип
Яныма кергәндер ул.
Чак кына какшап торганны
Ишетеп белгәндер ул.

Учына салып йөрәкне
Кысып, чеметеп карый,
Хәле бетеп туктап тора,
Ахры, куллары арый.

Капшап бавыр, бөерләрне,
Үпкәләргә сузыла.
Нәфсең тәмам азган икән,
Минем яннан шу гына!
Вакытымны әрәм итеп
Йөрмә әле, Газраил!
Бозыклыгым булса әгәр,
Җәлләп торма,җәза бир.

Тавык чүпләсә дә бетмәс
Эшемә аяк чалма.
Мине, карт-коры дип түгел,
Ир уртасы дип сана!

Оныкларым буйга җитте,
Килен төшерәсем бар.
Балаларын үчтек итеп,
Назлап үстерәсем бар.

Шәм кебек бүрәнәләрдән
Өйләр күтәрәсем бар.
Төпчегемнең алтын туен
Җырлап үткәрәсем бар.

Яннарыма килүеңнең
Аңламадым сәбәбен.
Оҗмах кошы – улыбызга
Җиткер кайнар сәламем!

Кайчак ялгышып китәсең,
Яшь гомерләр өзелә.
Гел-гел кан-яшь түктермәче,
Бүтән эш тап үзеңә!

## БАЛЫК ТОТКАНДА

"Тьфү, тьфү, балык, кап!" – дип
Төкерде кармагына.
Ыргытты суга. Тик кармак
Кадалды бармагына.

Суалчанын көйләде дә
Суга ташлады тагын –
Яр башында ятсын балык
Күзләрнең алып явын!

Төкереп балык ыргыту
Электән калган гадәт.
Күпме көтеп тә балык юк,
Нәрсәдә икән сәбәп?

Югыйсә, суалчанның да
Куйган иде хәллесен,
Кычыткан төбендәгесен,
Иң симезен, тәмлесен.

Юк, чиртми дә чиртми балык,
Калкавыч тып-тын йөзә.
Кармагыннан күзен алмый,
Малай түзсә дә түзә.

Көтмәгәндә яр астыннан
Килде бер сәер тавыш.
Әллә берәрсе эндәште,
Әллә ишетте ялгыш.

Ялгыш түгел, чын икән ич
Ныклап тыңлап караса.
Кушбаш та нәкъ кеше кебек
Сөйли икән ләбаса!

— Судан чыгып яр башында
Ятар идем ялтырап.
Шактый күптән сырхап торам,
Тәнем яна калтырап.

Мин яшен яшәгән инде,
Сүз юк минем турыда.
Туып бер яшькә дә җитми
Балаларым кырыла.

Я үлек булып туалар,
Кайсы дөнья гарибе.
Тик кешеләр аңламыйлар
Йөрәгемнең әрнүен!

Кара әле минем тәнгә:
Тәңкәләрем сап-сары!
Һәр тәңкәмдә еллар эзе,
Пычрак елга таплары.

Елгаларның яме китте,
Югалды суның тәме.
Шулай пычрак буламыни
Судагы балык тәне?!

Куышып уйнарга иде
Чиста елга суында.
Су белән Балык язмышы
Сез – кешеләр кулында!..

Ышансынмы балыкчыбыз
Бу Кушбашның сүзенә.
Әнә бит, тынчу елганы
Күреп тора үзе дә.

Күреп тора: фермалардан
Аммиак төшә агып.
Нефтьчеләр тозлы суны
Агыза җаен табып.

Химикатлы гөрләвекләр
Суга төшә юл ярып.
Елгада тирес, үләксә... –
Ничек тын алсын балык?!

Елгага ташланган күпме
Пыяла, черек калай?! –
Су кергәндә табан астын
Ярды берничә малай...

Коточкыч сынауларга да
Түзсә дә түзә елга.
Тик тереклек иясенең
Язмышы тора кылда.

Ярдәм кирәк Табигатькә!
Дәшәм сезгә – яшьләргә:
Җир саулыгы – сезнең кулда,
Сезгә кирәк яшәргә!

# ҮЗЕМ ТУРЫНДА СҮЗЕМ

Мин, ФАЗЛЫЕВ Мөнәвир Ибраһим улы, 1934 елның 7 апрелендә Башкортстанның Яңавыл районы Истәк авылында крестьян гаиләсендә туганмын. Яңавыл беренче санлы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында (татар теле һәм әдәбияты бүлеге) белем алдым. Диплом эшем "Шәехзадә Бабич иҗатында юмор һәм сатира" дигән темага иде. Ш.Бабичның әсәрләрен күпсанлы архив материалларыннан җыеп, туплап, аңлатмалар биреп, 1958 елда Казанда бастырып чыгардык. Филология фәннәре докторы, профессор, татар әдәбия-

ты кафедрасы мөдире Хатип ага Госман бу юнәлештә зур эш башкарды. Ул Ш.Бабичның "Сайланма әсәрләр"енә бик эчтәлекле итеп баш мәкалә язып чыкты. Әлеге китапның әһәмияте зур булуы турында аңлатып торуның кирәге юктыр, мөгаен. Тик шуны әйтеп үтәсем килә: Ш.Бабичның әсәрләре утыз алты ел буена китап булып басылып чыкмаган, халык бу зур әдипнең әсәрләрен укудан һәм өйрәнүдән мәхрүм ителгән иде...

Кечкенәдән әдәбиятны, театрны ярattым. Үзем дә, үзешчәннәр белән бергә, концертларда, спектакльләрдә катнаштым. Район смотрларында җиңеп, республикабыз башкаласы Уфада да чыгышларыбызны җылы кабул иткәннәре булды. Ә шигырьләргә килгәндә... "Алар минем гомерлек юлдашларым булдылар", – дисәм – тары бөртеге кадәр дә арттыру юк монда. Башлангыч сыйныфларда ук шигырьләр яза идем инде. Стена газетасында, соңрак район газетасында да басыла башладылар алар. Шигърияткә тартылуымда бертуган Газимә һәм Нәгыймә апамнар җитди роль уйнады. Алар, бербер артлы, почтальон булып эшләделәр. Шулар алып кайткан гәҗит-журналларны укып, кызыклы шигырьләрне ятлый торган идем.

Аеруча Әниемә, Әтиемә рәхмәтлемен. Алар сәнгатьне сөяләр иде һәм безне дә пакьлеккә, гыйлемгә, нәфислеккә җәлеп итәргә тырыштылар. Әнидән "Сак-Сок" бәетен, "Ахырзаман", "Мәүлит" һәм башка мөнәҗәтләрне тыңлап үстем. Әнием гарәп графика-сында укый-яза белә иде. Туксан өч яшендә, үләренә берничә көн калгач, "Картлык көннәре" дигән мөнәҗәтен көйләп ишеттерде.

Хәләл җефетем Рәшидә Закирҗан кызы белән, бер үк уку йортын тәмамлап, үзебезнең туган авылда гомеребез буе мәктәптә укытучы булып эшләдек. Әдәбият-сәнгать юлыннан да бергә җитәкләшеп атладык.

Туганнарым да, балаларым да җырга, биюгә, әдәбиятсәнгатькә мөкиббән.

Университетта укыганда редакцияләргә кергәләп йөри идек. Язучыларның Г.Тукай исемендәге клубына "Әдәби җомга"ларга бара, шагыйрьләр, язучылар белән таны-

ша идек. Сабакташым – мәрхүм Әнвәр Мәүлиханов белән якташларыбыз Нурихан Фәттах, Нил һәм Илдар Юзеевлар янына барып чыга һәм бик күңелле итеп кичләрне уздыра торган идек.

Илленче еллар уртасында, шигырь тотып, якташ шагыйрь Зыя Мансур янына редакциягә барып кердем. Анда Шәйхи Маннур, Сафа Сабиров һәм башка әдипләр бар иде. Зыя Мансур шигыремне кычкырып укып чыккач, Шәйхи Маннур, җанлана төшеп:

— Тагын бер кат укы әле, бик әйбәт язылган бит бу! – дип үз бәһасен бирде. – Хәзер үк, чираттагы санга бирик без аны!..

Күп тә үтми шигырем "Чаян" журналында басылып та чыкты.

Әдипләр яшьләргә бик игътибарлылар иде ул заманда.

Сабакташым Әнвәр Мәүлихан белән (ахирәтемнең урыны җәннәттә булсын!) Хәсән Туфанның (аның, акланып, яңа кайткан чагы иде) Бауман урамындагы фатирына өстәл, урындыклар һәм, "Урал-1400" иде булса кирәк, радиоприемник (озын, зур иде ул) кертеп урнаштырдык. Күпне күргән әлеге шагыйрьнең гадилеге һәм тыйнаклыгы безне аеруча сокландырды.

Атаклы гармунчы Фәйзулла ага Туишевның соңгы концер-тында булу бәхетенә дә ирештек. Искитмәле, йөрәкләрне тетрән-дергеч концерт иде бу! Аның тылсымлы гармуннары аһәңе әле дә колак төбемдә чыңлап тора.

Укутучыларыбыз Хатип ага Госман, Латиф ага Җәләй, Якуп ага Агишев, Диләрә ханым Тумашева безне әдәбиятның, телнең тылсымлы серләренә төшенергә өйрәттеләр. Ә Мирфатих Зәкиев, Нил Юзиевлар күңелдә җуелмас эз калдырдылар. Кешелекле дә, кечелекле дә иде остазларым.

Хатип ага, авырып китсә дә, диплом эшемнең ничек барышы турында сораштыру өчен өенә чакыртып ала торган иде. Ул бик җентекле тикшерә, күрсәтмәләр бирә, эшләнгән эшне объектив бәяли иде. Аннары:

— Марфа (хәләл җефетенең исеме шулай иде – М.Ф.), студентны пылау белән сыйлап җибәр әле, ачыккандыр! – дип, табын янына чакыра һәм кыстый-кыстый ашата

иде. Авыруы җиңеләйгән көннәрдә Хатип ага мине озата чыга, сөйләшә-сөйләшә юкәләр арасыннан атлыйбыз. Агачларга мул булып бәс сарган – алар, ап-ак чәчәкләр кебек, күзләрнең явын алып торалар. Юкәләрне Хатип ага тотып-тотып селкетә, өстебезгә ак карлар коела. Табигатьнең мондый хозурлыгы аны дәртләндереп җибәрә иде...

Яңавылга кайткач, район газетасы редакциясендә эшләп алдым. Аннары туган авылыма мәктәп директоры итеп җибәрделәр. Утыз елга якын мәктәп директоры һәм авыл Советы башкарма комитеты рәисе булдым. "Россия Федерациясенең мәгариф отличнигы" дигән мактаулы исем дә бирделәр үземә. Тел һәм әдәбият, тарих укытучысы булып эшләдем. Бүгенге көндә тарих укытам.

Шигырьләрем үзебезнең район гәҗитеннән тыш, "Кызыл таң", "Өмет" (Уфа), "Татарстан яшьләре", "Шәһри Казан" газеталарында газеталарында басылды, балалар матбугаты битләрендә урын алды.

Байтак шигырьләремә композиторлар көйләр дә яздылар...

Үзем турында кыскача менә шулар. Калган әйтер сүзем – язылган һәм языласы шигырьләремдә... Сезнең белән кабат очрашулар теләп калам, хөрмәтле укучыларым!.. Сау-сәламәт һәм бәхетле булыйк!..

Мөнәвир ФАЗЛЫЕВ

# Эчтәлек

**ШИГЫРЬГӘ МӨКИББӘН КҮҢЕЛ (Кереш сүз. Зәет Мәҗитов)** ..................... 3
**ЯГЕЗ, АВЫЗ ИТИК!..** ..................... 5
**ВАКЫТ ТИЗЛЕГЕННӘН УЗ, КҮҢЕЛЕМ!.Лирик шигырьләр** ..................... 6
ВАКЫТ ТИЗЛЕГЕННӘН УЗ, КҮҢЕЛЕМ!.. ..................... 6
АГЫМ СУЛАР ..................... 7
ГӨЛБАДРАНКАЙ ..................... 7
БӘЛКИ, ГАФУ ИТӘРСЕҢ... ..................... 8
ЧИШМӘКӘЙ ..................... 8
КИТМӘС ИНДЕ ..................... 9
ӨЗМӘ ЧӘЧӘКЛӘРНЕ ..................... 9
КӨЗГЕ ГӨЛЛӘР ..................... 10
ТЫҢЛАРМЫН ..................... 10
ӨЙ ТОРА КӨЛЕП КЕНӘ ..................... 11
ДӨНЬЯ МАТУР ..................... 12
ЯҢАВЫЛ ПЛЮС КАЗАН ..................... 13
КИТМӘГЕЗ, КЫЗЛАР... ..................... 13
ЯРАТАМ МИН ТУГАН АВЫЛЫМНЫ ..................... 14
ШАЯРТУ ..................... 14
ТЕЛЕВИЗОР ..................... 15
ИЗГЕ ҖАНЛЫ ӘЛФИЯ ..................... 16
ЧӘЧӘКЛӘР ..................... 16
ТАМЧЫЛАР ..................... 17
ЙОЛДЫЗЛАР – КҮРӘЗӘЧЕ ..................... 17
КАЙДА СОҢ СЕЗ? ..................... 18
ЭЗЛИМ ..................... 18
НИГӘ, ӘТКӘЙ, МОҢЛАНДЫҢ?..................... 19
ӘНКӘЙ ПЕШЕРГӘН ИКМӘК ..................... 20
МӘХӘББӘТЕҢ БУЛСА ..................... 21
ТЕПЛОВОЗ ..................... 21
СОЛДАТ УЛЫМ – ИЛНУРЫМ ..................... 22
КУАНАМ МИН..................... 24
ЯШЕРМӘ КАРАШЫҢНЫ ..................... 25
ИСТӘК – ТУГАН АВЫЛЫМ ..................... 25
ЧӘЧӘКЛӘР УТЫРА ТЫН ГЫНА ..................... 26
ЯТСЫНМА ..................... 27
АВЫЛ ..................... 27

БӘНЗИР ГАЛИНГА ........................................ 28
ЮЛДА ........................................................... 28
ТАҢНАРДА ТОРЫП ......................................... 29
КАЙДА, КАЙДА МИНЕМ МӘХӘББӘТЕМ? ............ 30
КӨТМӘГӘНДӘ ТАШЛАП НИК КИТТЕҢ? ............ 30
ТЕЛӘК ......................................................... 31
ЮЛГА ЧЫКСАМ .............................................. 31
САГЫНАМ СИНЕ, ӘНКӘЙ!.. ............................ 32
ТУКТАП ТОРЫЙК, ТЫҢЛАП ТОРЫЙК... .......... 33
ҖЫРЛАР ОЧЫРАМ ӘЛЕ .................................. 33
«ӨМЕТ»КӘ .................................................... 34
СҮЗЛӘР – ГӘРӘБӘ ........................................ 35
КУРКАМ... .................................................... 35
БӘБИ ТУЕ .................................................... 36
ТОРМЫШМЫНИ? ............................................ 36
КАРА БОЛЫТ ................................................ 37
ЙОМГАК ЯСЫЙМ ............................................ 37
ХАСТАХАНӘДӘ .............................................. 37
ТЕАТР .......................................................... 38
АВЫЛДА ҖӘЙ ................................................ 39
ГЕЛ ШУЛАЙ КӨТӘ СЫМАН .............................. 40
КЫШ ............................................................ 41
ШИФАЛЫ КӨЧ БАР БЕЗДӘ .............................. 41
АКЧАРЛАК .................................................... 42
САБАНТУРГАЙ ................................................ 43
МИН ДӘ АДӘМ БАЛАСЫ .................................. 43
АККОШЫМ ..................................................... 44
**АКЫЛЛЫ СЫЛУКАЙЛАР** ................................ 44
БЕРЕНЧЕ СЕНТЯБРЬ ...................................... 45
АКЫЛЛЫ СЫЛУКАЙЛАР .................................. 45
КЕЧКЕНӘ КЫЗ ГӨЛГЕНӘ ................................ 47
АК КАЕН ЗАРЫ ............................................. 48
УРАЗА ТОТАСЫҢ КИЛСӘ... .............................. 49
И, ШАМИЛ... ................................................. 49
САБЫР ТӨБЕ ................................................. 50
МОГҖИЗА ...................................................... 50
ФӘРЕШТӘ ...................................................... 51
УЯН ИНДЕ ЙОКЫҢНАН!.. ................................ 51
ЭЗЛӘП ТАПТЫК .............................................. 52
МАЛАЙЛАРГА НӘРСӘ КИРӘК? ........................ 53

КӨЗ ........ 54
ДӘФТӘР ҖЫЛЫЙ ........ 54
КҮРШЕЛӘРЕМ ........ 55
ТУГАН КӨН ........ 56
ӨЙРӘНӘБЕЗ ТУГАН ЯКЛАРНЫ ........ 57
АКТҮШ ........ 57
АЙ ҮСӘСЕН БЕР КӨНДӘ ҮС... ........ 58
КЫЗЫМ ИЛМИРАГА ........ 59
ГАРМУН УЙНЫЙ КЫЗ БАЛА ........ 59
ЙӨЗЕК КАШЫ ........ 60
МАЛАЙЛАР ........ 61
ВЕТЕРАН КОСТЮМЫН КИЯ ........ 62
**ОЧЫ БЕР ЧЫГА! (Юмор һәм сатира)** ........ 64
ШУНДА МӘХШӘР ВӘ ТӘМУГЪ ........ 64
РЕФОРМА ........ 65
ХӘЙЛӘЛӘ ........ 65
"ЗАПАРАЙ"НЫ РЕМОНТЛАГАНДА ........ 66
ПЕШӘ ТОРА... ........ 67
НӘФЕС ........ 67
БЕР ЕГЕТ ........ 68
КӨТӘЛӘР ........ 69
ҖӘП СӨРГӘНДӘ ........ 70
ТӨТЕН ........ 70
КҮЗЕҢ ТӨШТЕМЕ ӘЛЛӘ? ........ 71
ӘТИ БУЛДЫМ МИН БҮГЕН! ........ 71
МАШИНАЛАР КИТТЕ ГӨЖЛӘП ........ 73
МУТЛЫК ........ 75
ДОЛЛАР ........ 75
ОНЫТКАН ........ 76
СӘРХҮШ ........ 77
ҖАЕН ТАПКАН ........ 78
НЛО ........ 80
АШХАНӘДӘ ........ 81
ГАЛИУЛЛА – МӨДИР БЕЗДӘ ........ 82
ОЧЫ БЕР ЧЫГА, ДИМӘК... ........ 84
БАР БИТ УЛ... ........ 85
ӨЙЛӘНДЕМ ........ 85
ЯРАТАМ ........ 86
ГАЗРАИЛ ........ 86
БАЛЫК ТОТКАНДА ........ 88
**ҮЗЕМ ТУРЫНДА СҮЗЕМ** ........ 90



ФАЗЛЫЕВ Мөнәвир Ибраһим улы, 1934 елның 7 апрелендә Башкортстанның Яңавыл районы Истәк авылында туа. Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында (татар теле һәм әдәбияты бүлегендә) белем ала.

Яңавылга кайткач, район газетасы редакциясендә эшли. Аннары туган авылына мәктәп директоры итеп җибәрелә. Утыз елга якын мәктәп директоры һәм авыл Советы башкарма комитеты рәисе була. Россия Федерациясенең мәгариф отличнигы дигән мактаулы исемгә лаек була. Тел һәм әдәбият, тарих укытучысы булып эшли. Бүгенге көндә тарих укыта.

"Хәтер" нәшрияты